# ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ ӨЙРӘТКӘН КӨНДӘЛЕК ДОГАЛАР

РӘҮФ ПӘҺЛЕВАН

МОТИФ ЙАЙЫНЛАРЫ

www.darul-kutub.com

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

# КЕРЕШ СҮЗ

«Дога» сүзенең лексик мәгънәсе чакыру, эндәшү, теләү, өндәү, ярдәм сорау, исем бирү, ялвару, үтенү, сыену дигәнне белдерә.

Доганың асыл мәгънәсе: «Дога – колның бөтен барлыгы белән Аллаһ Тәгаләгә юнәлеп, нәрсәнең дә булса үтәлүен яки үтәлмәвен, Аллаһка мәдхия һәм мактау әйтеп, гаҗизлеген һәм ихтыяҗын тел белән белдереп сорау, Аннан теләү».

Дога кеше белән Аллаһ арасында хәбәрләшү яки аралашу буларак

www.darul-kutub.com

билгеләнергә дә мөмкин. Беренче карашка, әлеге аралашу берьяклы булып күренә. Әмма догада бары тик дога кылучы гына аңлый алырлык бер юл белән Аллаһның моңа җавап бирүен көтү һәм өметләнү бар.

Вахи Аллаһ белән кеше арасында югарыдан түбәнгә таба, ягъни Аллаһтан кешегә таба баручы үзенчәлекле әңгәмә. Ә дога кеше белән Аллаһ арасында булган түбәннән югарыга таба юнәлештәге үзенчәлекле әңгәмә.

Дога колның Аллаһка ялваруы һәм сыенуы, Аллаһның колын мәрхәмәте белән ярлыкавы һәм саклавы буларак та билгеләнә.

Исламча караш буенча, Яратучы белән мәхлуклары арасында мөнәсәбәт булганга, кешенең барлык гамәлләре, нинди булуларына да карамастан, дога рәвешендә керә. Коръән Кәримдә бу хакта әйтелгән:

«Әйт: «Әгәр Аллаһка ялваруыгыз һәм гыйбадәтегез булмаса, Аллаһ сезнең белән нәрсә эшләр иде, ягъни Аллаһка гыйбадәт кылмасагыз һәм итәгать



www.darul-kutub.com

итмәсәгез, Аңа ни өчен кирәксез?» («Фуркан» сүрәсе, 77 нче аять)

«Дога рәвешендәге Аллаһ-кеше диалогында Аллаһ колына һич ялгышмыйча җавап бирә» (Гафир сүрәсе: 60 нчы аять). Аллаһ колына муен тамырыннан да якынрак булганга күрә, дога кылуда кешегә кычкырып дәшәргә, бәргәләнергә, матур сүзләр, нәфис җөмләләр белән мөрәҗәгать итәргә кирәкми. Доганың әһәмияте сүзләрдә түгел, дога кылучының ихласлылыгы һәм эчкерсезлегендә.

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм Мәккәдән Таифкә баргач, башыннан аякларына кадәр яраланган. Кайтыр юлга чыккач, кереп яшеренгән бер бакчада дога кылган:

«Аллаһым! Көчсезлеккә юлыгуым, чарасыз калуым, халык тарафыннан хур ителүем турында Сиңа гына белдерәм, бу хакта Сиңа гына шикаять итәм.

Әй, мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе! Син мазлумнарның Раббысы!



www.darul-kutub.com

Аллаһым! Начар холыклы, оятсыз дошманнар кулына төшермәслек, хәтта туганнарым кулында булган тормышымның тезгеннәрен алардан алып, дустыма калдырмаслык дәрәҗәдә миңа мәрхәмәтлесең.

Аллаһым! Әгәр миңа газаплар бирмәсәң, тарыган бәлаләргә һич бирешмәм. Ләкин Синең мине саклавың боларны күрсәтмәслек дәрәҗәдә киң. Сиңа гына сыенам. Синең ягымлылыгыңның нурына сыенам. Барлык караңгылыкларны да яктырткан, дөнья һәм ахирәт эшләренең яхшы якка үзгәртүче бары тик Аңа бәйле булган нурга сыенам.

Аллаһым! Син риза булганчыга кадәр мин ярлыкау сораячакмын. Бөтен куәт, һәр төрле кодрәт бары тик Синдә генә».

Дога һәм үтенечебезнең башы да, ахыры да Аллаһ Тәгаләгә мактау әйтүдән гыйбарәт.

***Рәүф ПӘҺЛЕВАН ГҮР***

***Истанбул-2002***

www.darul-kutub.com

# ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ СӨННӘТЕНДӘГЕ ДОГАЛАР

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләмгә һәм аның тормышына күз салсак, доганың аның тормышындагы һәр мизгелендә очрый торган гамәл булуын күрәбез. Дога аның тормышында гадәти бер яшәү рәвешенә әйләнгән.

Хәзрәти Мөхәммәднең кайбер хәдисләрендә дә доганың әһәмияте аңлатылган:

«Дога – гыйбадәтнең җилеге» (Тирмизи, «Тәфсир»: 16)

«Аллаһ каршында догадан башка ихтирамга лаек берни дә юк» (Тирмизи, «Дәгъват»: 1)

«Дога гыйбадәтнең асылы?» («Тохфәту-л Ахвәзи»: 9/311)

«Дога иңгән бәла-казалардан да, иң-

www.darul-kutup.com

мәгән бәхетсезлекләрдән дә саклый. Аллаһның коллары! Сезгә кирәк булган догадан туктамагыз». («Әт-Тадж»: 5/101)

«Һәлакәттән бары тик дога гына коткарырга мөмкин. Гомерне дә бары тик хәерле гамәлләр генә озайта ала». («Әт-Тадж»: 5/101)

«Куркыныч вакытларда һәм кыенлыкларга юлыкканда догасының Аллаһ тарафыннан кабул ителүен теләгән кеше, тыныч-имин вакытта да, муллыкта да күп дога кылсын». («Тохфәту-л Ахвәзи»: 9/324)

«Аллаһның мәрхәмәтеннән теләгәнегезне сорагыз. Хакыйкатьтә, Газиз һәм Җәлил булган Аллаһ үзеннән сораганны ярата. Гыйбадәтнең иң кыйммәте дә ярлыкануны сорау». («Әт-Тадж»: 5/101)

«Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм әйткән: «Гөнаһлы нәрсәләр яки туганлыкка каршы дога кылмаган очракта, җир йөзендә догасы Аллаһ тарафыннан кабул ителмәгән

www.darul-kutub.com

бер генә мөселман да юктыр. Аллаһ, һичшиксез, сораган кешене теләгенә ирештерер яки үзеннән шул яманлыкны кире чигерер», – дигән. Моңа каршы бер кеше: «Алайса без күп итеп дога кылыйк», – дигән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм: «Аллаһның ярдәме чиксез», – дигән. («Әт-Таҗ»: 5/100)

«Дога – мөселманның коралы, диннең терәге, күкләрнең һәм җирнең нуры». («Әт-Тәргыйб»: 2/479)

«Дога кылуда гаҗиз булмагыз. Чөнки дога кылган затлар беркайчан да һәлак булмас». («Әт-Тәргыйб»: 2/479)

«Кол: «Йә, Раббым! Йә, Раббым! Йә, Раббым!» дигән саен, Аллаһ Тәгалә аннан: «Колым! Ни телисең? Сора!» дип әйтер һәм сораганын бирер». («Әт-Тәргыйб»: 2/448)

«Кем Миңа дога кылмаса, Мин аңа ачулы булырмын». («Фәйзу-л Кадир»: 4/497)

Аятьләрдәге кебек, хәдисләрдә дә

доганың фазыйләте, өстенлеге, кагыйдәләре, шартлары, кабул ителүе мөмкин булган һәм булмаган догалар, дога кылу өчен уңайлы вакыт, Хәзрәти Мөхәммәднең төрле урыннарда һәм вакытта, төрле хәлләрдә кылган үзенчәлекле догалары хакында мәгълүмат бирелгән. Ислам мәдәниятендә Коръән Кәримдә китерелгән дога аятьләре һәм хәдис чыганакларында бирелгән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләмнең догалары белән бергә пәйгамбәрләргә һәм борынгы изгеләргә кагылышы булган дога текстлары «мәэсүр догалар» дип атала. Догаларга бәйле рәвештә барлыкка килгән әдәбиятның җыентыкларга кертелгән иң әһәмиятле һәм иң күләмле бүлеген «мәэсүр догалар» тәшкил итә.

www.darul-kutub.com

# ДОГА ТӨРЛӘРЕ

## 1. Шөкер догасы

Аллаһның чиксез мәрхәмәте һәм икрамына карата кешенең буйсынучан хәлен һәм тойган хисләрен белдерүенең иң кулай ысулы шөкер догасы була. Шөкер итү доганың иң уңайлы һәм киң таралган белдерелүе. Гадәттә, кешеләр үзләренә бирелгән бүләкләр һәм ярдәм иткән өчен рәхмәт әйтәләр. Үзебезнең бар булуыбыз белән бергә тормышыбызны дәвам иттерү өчен кирәкле ихтыяҗларыбызны һәм яшәешебезне матурлаган, ләззәт һәм кыйммәтле нәрсәләр белән тулыландырган, исәпсез нигъмәтләрне чиксез рәвештә тәэмин итеп һәм әзерләп торган Илаһи чыганакның бүләкләренә җавап рәвешендә сүз белән рәхмәт белдерү. Шөкер кешенең

www.darul-kutub.com

үзенә ирешкән нигъмәтләрне төшенүе һәм моны белдерүе дигәнне аңлата. Коръән Кәрим Аллаһның чиксез нигъмәтләрен кулланган кешенең бу нигъмәтләрнең хуҗасы кем булуына төшенүен һәм хезмәте өчен бирелгән нигъмәтләр нәтиҗәсендә ирешкән бәхет-шатлыгын рәхмәт әйтеп билгеле рәвештә белдерүен шөкер итү дип аңлата. Төрек телендәге «тәшәккүр» һәм «шүкран» сүзләре дә «шөкер» тамырыннан ясалган. Ислам терминологиясендә «шөкер»нең капма-каршы мәгънәсе «көфер» дигән сүз белән белдерелгән. Көфер биргән нигъмәтләргә игътибар итмәү, оныту, инкарь итү, Аллаһның хөкем һәм нигъмәтләрен инкарь итү дигәнне аңлата.

Шөкер Аллаһка ышануның бер күрсәткече буларак бәяләнә. Коръән Кәримдә дә биргән нигъмәтләргә шөкер итә белүе кешенең типик үзенчәлекләреннән берсе буларак тасвирланган. Кешеләрнең

шөкер итүе турындагы аятьләрнең саны егермегә якын.

Ислам әхлагында шөкернең тел белән әйтелүенә «тахдис-и нигъмәт», ягъни «нигъмәтләрне сөйләү» диелә. «Зуха» сүрәсенең 11 нче аятеннән алынган әлеге тәгъбирнең асыл мәгънәсе, төп ышану буенча, үзебезгә бирелгән нигъмәтләрдән башкаларга да өлеш чыгарудан гыйбарәт. Коръән Кәрим шөкер итүнең гамәл һәм хезмәт күрсәтү рәвешендә булуын ачык белдергән. «Әй, Дауд балалары, Аллаһның нигъмәтләренә шөкер итегез! Биргән нигъмәтләребезгә чынлап шөкер итүче кешеләр, бәндәләребездән аздыр» («Сәба» сүрәсе, 13 нче аять)

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм дә бу хакта әйткән:

«Аллаһ колына бер нигъмәт бирелгәндә, кол аның ишарәтен үзендә күрергә тели».

www.darul-kutub.com

## 2. Үтенү һәм теләү догасы

Кеше өчен догада беренчел фактор булып шәхси теләге һәм ихтыяҗлары тора. Күпчелек очракта чарасызлык һәм мохтаҗлык эчендә калган, курку һәм ышанычсызлыктан каушаган кеше өчен алар ярдәм сорау мөрәҗәгате була. Һәр очракта ялвару яки таләп итү догага хас үзенчәлек буларак тасвирлана. Уңыш, шифа, ышанычлылык һәм мадди уңайлыкларга ирешү өмете, хисси мәсьәләләрне чишү теләге һәрвакытта да догага кагылышлы темалар булырга мөмкин. Ләкин бу төрдәге догалар, югарыда әйтелгәнчә, кайвакыт иман каршылыгына барып тоташкан психологик проблемаларга да китерергә мөмкин.

Болар табигатьләре белән эгоистик булганга күрә, нәтиҗәләре һәрвакытта да дини аң үсешенә тәэсир итмәскә мөмкин.

www.darul-kutub.com

## 3. Аллаһтан гафу сорау (истигъфар) догасы

Аллаһтан гафу сорау, гөнаһларны тану өчен кылына торган дога. Аллаһка якын булу һәм Аның ризалыгына ирешерлек гамәлләр кылуны дәвам итәргә теләү кайбер дога төрләренең сәбәбе була. Бу күзлектән караганда, кешеләр үзләрен Аллаһтан ерак күргәнгә, әлеге аерылуны борчылу, тәүбә һәм истигъфар (гафу ителү) таләбе белән төзәтмәкче тырышалар.

«Тәүбә»нең лексик мәгънәсе «гөнаһны кире кагу, гөнаһсызлык халәтенә кайту» дигәнне аңлата. Ислам әдәбиятындагы мәгънәсе: «кешенең гөнаһлы хәлен калдырып, гөнаһсызлык хәленә кайтуы, кылган гөнаһы өчен борчылуы, бүтән моны эшләмәскә тырышуы».

Тәүбәгә якын мәгънәле сүзләрдән берсе – «истигъфар». Истигъфар колның Аллаһтан үзен газаптан саклавын сора-

www.darul-kutub.com

вы мәгънәсендә килә. Бу теләкнең бары тик сүздә генә булуы җитми. Газапка китерә торган гамәлләрдән ерак тору кирәк. Коръәндә тәүбә һәм истигъфарны әмер итүче, Аллаһның тәүбәләрне кабул итүче булуын белдергән бик күп аятьләр бар. Сүз белән генә «тәүбә итәм» дип әйтү җитми. Тәүбә итүче кылган гөнаһларыннан чын күңелдән борчылырга, бүтән моны эшләмәскә вәгъдә итәргә һәм үзен үзгәртергә тиеш. Коръәннең күп кенә аятьләрендә тәүбә иткәндә, беренче чиратта, үзеңне үзгәртергә һәм изге гамәлләр кылырга кирәк диелгән.

«Алар бу кабәхәт эшләре өчен Аллаһтан фетнә яки газап ирешмәс дип хисап кылдылар. Туры юлны күрүдән күзләре сукыр булды, хак сүзне ишетүдән колаклары саңгырау булды. Аннары Аллаһ аларның тәүбәләрен кабул итеп, гөнаһларын гафу итте. Янә аларның күбрәге күзсез һәм саңгырау булдылар. Аллаһ аларның кыл-

www.darulkutub.com

ган эшләрен күрүче». («Маидә» сүрәсе, 71 нче аять)

Бер аятьтә: «Әй, мөэминнәр, Аллаһка тәүбә итегез чын ихлас тәүбә белән, ягъни кылган гөнаһларның һәммәсе өчен үкенеп, Аллаһтан гафу сорау белән» («Тәхрим» сүрәсе, 8 нче аять) диелгән. «Насух» сүзенең ике төрле мәгънәсе бар:

1. Ихлас, эчкерсезлек, сафлык, самимилек.

2. Тишелгән һәм ертылганны тегү яки ямау. Шуңа күрә тәүбә эчтән һәм самими борчылу да, гөнаһларны кире кагып, хәлне төзәтү дә була. Гөнаһның кеше шәхесенә тәэсир иткән зарарын бетерү шул рәвешле ямау һәм төзәтү инде ул.

Тәүбә бары тик җәза куркынычыннан яки гөнаһның җирәнгечлегеннән генә кылынмый, гөнаһның Аллаһка каршы чыгу, баш күтәрү булганга, Аллаһ алдында гаепле булу аркасында вөҗдан газабы кичерү сәбәпле ярлыкау сорала.

## 4. Гыйбадәт һәм мактау догасы

Дөнья төзелеше, матурлыклары һәм Яратучының илаһи чагылышларын таныган, төшенгән мөселман бу халәттә тойган ихтирам һәм соклану катыш курку хисләрен тавыш белән яки эчтән генә әйтә. Әлеге дога төрендә Аллаһка мөрәҗәгать таләп рәвешенә күчә. Ягъни Аллаһ башкарачак һәм макталачак Барлык буларак күзаллана һәм моннан тыш башка бернинди ният тә, максат та күздә тотылмый.

«Хәмед» (мактау) изгелек чыганагы булган бөек затны мактау; «тагъзим» (олылау, хөрмәтләү) шөкер итү максаты белән берәүне мактау дигәнне аңлата. Ислам гыйлемнәре терминологиясендә исә барлык мәхлукларның үз телләре белән Аллаһы Тәгаләне мактауларына «хәмед» диелә.

«Хәмед» сүзенең мәгънәсе «мәдхия (мактау)» сүзенекенә караганда таррак. Мәдхия Яратучыга да, Ул барлыкка

www.darul-kutub.com

китергән мәхлукларга да карата әйтелергә мөмкин. Хәмед исә бары тик Яратучыга гына, ягъни Аллаһ Тәгаләгә генә адреслана. Мәсәлән, мәдхия энҗе, чәчәк, атка карата да әйтелә. Ләкин аларга хәмед әйтелми. Мәдхия бирәүгә нәрсәдер бирелгәннән соң да, бирелгәнчегә кадәр дә әйтелергә мөмкин. Хәмедне бары тик изгелек кылганнан соң гына әйтәләр. Әхлакка туры килмәгән теләсә кайсы нәрсәгә мәдхия әйтеп була, әмма аларга хәмед әйтергә ярамый. Хәмедне бары тик мәшругъ (шәригать кушканча) һәм әхлакка туры килә торган нәрсәләр өчен генә әйтәләр. Хәмед сүзенә мәгънәдәш тагын бер сүз – «шөкер». Галимнәр «шөкер»нең мәгънәсен «Аллаһның биргән нигъмәтләренә колның үз теле белән мактауга кушып әйткән рәхмәте» дип ачыклыйлар. Хәмед турында Коръән Кәримнең күп кенә аятьләрендә язылган. Бу сүз «Аллаһ» һәм Аллаһның сыйфатларыннан берсе булган «Раббы»

сүзе белән бергә кулланылган. Коръән Кәримнең беренче сүрәсе «Фатиха» «хәмед» сүзе белән башланган. Бу аятьтә хәмеднең бары тик Аллаһ Тәгаләгә карата гына әйтелергә тиешлеге турында әйтелә. Коръән Кәримдә хәмеднең бары тик Аллаһка карата гына әйтелергә тиешлеген белдергән аятьләрнең саны 38гә җитә. Менә аларның берничәсе:

«Чын мактау – җирне һәм күкләрне төзүче Аллаһка хас, янә ул караңгылыкны һәм яктылыкны бар кылды». («Әнгам» сүрәсе, 1 нче аять)

«Мактау бөтен галәмне тәрбияләүче Аллаһка тиешле». («Йоныс» сүрәсе, 10 нчы аять)

www.darul-kutub.com

## 5. Башка мөселманнар өчен кылынган догалар

Боларга «шәфәгать догасы» дип әйтелә. Кешеләр төрле хәлләрдә бер-берләренең ярдәменә мохтаҗ булалар. Мохтаҗлык кешеләрне бер-берләренә якынайта һәм бәйләп тә куя. Ярдәмләшү тойгысы белән яшәгән кешеләрнең матди, рухи һәм психологик файдаларга ирешү өчен кылына торган махсус догалары бар. Аларга Хәзрәти Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләмгә һәм кайбер вәлиләргә карата кичергән ихтирам һәм ярату хисләрен тел белән белдерү максатыннан кылына торган догалар керә. Болар пәйгамбәрләр аша Аллаһка якынлашу ниятен күздә тота.

Шәфәгать гөнаһкарьләр өчен үтенү, ялвару, сорау һәм арадаш булу дигәнне аңлата.

Ислам гыйлемнәре әдәбиятында шәфәгать ахирәт көнендә гөнаһкарь

www.darul-kutub.com

мөселманнарның гафу ителүләре һәм итәгатьле мөселманнарның тагын да югарырак дәрәҗәләргә ирешүләре өчен Пәйгамбәребез Мөхәммәднең һәм башка бөек затларның Аллаһ Тәгаләгә ялварулары һәм үтенүләре, шәфкать итүен сораулары дигәнне белдерә. «Шәфәгатьнең барчасы Аллаһка хас, Аның рөхсәтеннән башка һичкем шәфәгать итә алмас» («Зүмәра» сүрәсе, 44 нче аять). «Ахирәттә шәфәгать итүче булмас, мәгәр Аның рөхсәте соңында гына булыр» («Йоныс» сүрәсе, 3 нче аять). «Коръән белән гамәл кылмыйча, һәлакәтлекне кәсеп итүчеләр, исламга кяферлек кылганнары өчен, аларга җәһәннәм газабы һәм эчәргә пычрак, кайнар су булыр» («Әнгам» сүрәсе, 70 нче аять). Алар рәхмәт капкасы булган шәфәгатьтән файдалана алмаслар. Ахирәттә барлык кешеләр дә хисап тотканда һәм аларга хөкем чыгарылганда иң бөек шәфәгатьче булып Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм

www.darul-kutub.com

торачак. Ягъни шәфәгать капкаларын ул ачачак. Аның бу шәфәгате «Шәфәгат-и гүзъмә» (бөек шәфәгать) дип атала.

## Тәһарәт догалары

Тәһарәтләнер алдыннан «Бисмилләһ» әйтү сөннәт санала. Һәр әгъзаны юганда «Бисмилләһ» әйтү Тәһарәт кагыйдәләреннән була.

Тәһарәт алып бетергәч, Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллəллаһу галәйһи үәсәлламгә салават һәм сәлам әйтү сөннәт. Шәһадәт кәлимәсе белән дога әйтүнең мәндүб (кирәкле) булуын Хәзрәти Гомәрнең (Аллаһ аннан риза булсын!) Мөслим, Әбү Дауд һәм Ибне Маҗә тапшырган хәдисе раслый. Менә ул:

«Арагыздан берегез Тәһарәт алып, аны кимчелексез тәмамлагач, «Аллаһтан башка илаһ булмавына, Аның тиңдәше булмауга һәм Аның бер үзе генә булуына шәһадәт кылам һәм Мөхәммәднең

Аның колы һәм расүле булуына шәһадәт кылам» дигән шәһадәт сүзләрен әйтсә, аңа һичшиксез Җәннәтнең сигез капкасы ачылыр. Шуларның берсен сайлап керергә мөмкинлекләре булачак».

Хәдис китапларыннан алынган доганың ахыры шулай бирелә (бу дога Тәһарәт алганнан соң укыла):

أَشْهَدُ أَنْ لا إِلَهَ إِلاّ اللهُ وَحْدَهُ لا شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمّداً عَبْدُهُ وَرَسولُه. اللّهُمَّ اجْعَلني مِنَ التَّوّابينَ وَاجْعَلْني مِنَ المتَطَهّرين. سُبْحانَكَ اللّهُمَّ وَبِحَمدِك, أَشْهَدُ أَنْ لا إِلَهَ إِلاّ أَنْتَ, اسْتَغْفِرُكَ وَأَتوبُ إِلَيْكَ, و صَلَّى اللهُ وَ سَلَّمَ عَلَى مُحَمَّدٍ وَ عَلَى الِ مُحَمَّدٍ

**«Әшһәдү әл ләәәә иләәһә илләллаһу үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһ. Аллаһүммә җгальни минә-т тәүүәәбиинә үәҗгәлни минә-ль мүтәтаһһириин. Сүбхәәнәкаллаһүммә үә бихәмдик. Әшһәдү әл ләәә иләәһә иллә әңтә әстәгъфирукә үә әтүүбү иләйк. Үә**

www.darul-kutub.com

**салләллаһу үә сәлләмә галәәә Мүхәммәдиү үә галә әәли Мүхәммәд»**

*«Аллаһ Тәгаләдән башка Илаһи зат юклыгына, Аңа тиңнәр булмавына һәм бердәнбер Илаһ булуына шаһитлек кылам. Шулай ук Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләмнең Аллаһның колы һәм илчесе булуына шәһитлык кылам. Әй, Аллаһ Тәгаләм! Мине тәүбә кылучы һәм пакь бәндәләреңнән кыл! Дан Сиңа, йә, Раббым! Мактаулар Сиңа.*

*Шәһадәт кылам: Синнән башка иләһ юк. Мин Синнән гафу итүне сорыйм һәм тәүбә кыламын. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләмгә һәм аның гаиләсенә салават һәм сәлам әйлә».*

Имам Нәвави әйткәнчә, Тәһарәт алганда, гәүдә әгъзалары юылганда укыла торган догалар хәдисләргә нигезләнми. Тәһарәт алганда укыла торган әлеге догалар Сәләфтән[1] алынган. Аларны уку күркәм гадәт санала, мөстәхәб була.

---

*1 Сәләф-и Салихин (борынгы изге кешеләр) укыган һәм алар безгә тапшырып калдырган Тәһарәт догалары алга таба китерелә.*

## 1. <u>*Тәһарәт ала башлаганчы укыла торган дога:*</u>

الْحَمْدُ للهِ الَّذِى جَعَلَ الْمَاءَ طَهُورًا وَ جَعَلَ الْإِسْلَمَ نُورًا

**«Әлхәмдү лилләәһилләзии җәгалә-ль мәәә-ә таһүүрау үә җәгалә-ль исләәмә нүүра»**

*«Суны пакьләндергән һәм Исламны нурландырган Аллаһка мактау булсын»*

## 2. <u>*Авызга су алганда әйтелә:*</u>

اللَّهُمَّ أَسْقِنِى مِنْ حَوْضِ نَبِيِّكَ كَأْسًا لاَ أَظْمَأُ بَعْدَهُ أَبَدًا

**«Аллаһүммә әскыйни миң хәүдый нәбиййикә кәэсән ләәә әзъмә-ү бәгьдәһү әбәдән»**

*«Йә, Аллаһым! Миңа Пәйгамбәребезнең хәвызыннан (сулыгыннан) бер касә су бирсәң, аннан соң мәңге сусамас идем»*

## 3. <u>*Борынга су алганда укыла:*</u>

اللَّهُمَّ لاَ تَحْرُمْنِى رَايِحَةَ نَعِيمِكَ وَ جِنَانِكَ



www.darul-kutub.com

**«Аллаһүммә ләә тәхрумни раихәтә нәгиимикә үә җинәәник»**

*«Йә, Аллаһым! Мине нигъмәтләреңнән һәм Җәннәтеңнең хуш исләреннән мәхрүм калдырма»*

## *4. <u>Битне юганда әйтелә:</u>*

اللَّٰهُمَّ بَيِّضْ وَجْهِى بِنُورِكَ يَومَ تَبْيَضُّ وُجُوهٌ وَ تَسْوَدُّ وُجُوهٌ

**«Аллаһүммә бәййидъ үәҗһи бинүүрикә йәүмә тәбьйәдду вүҗүүһүн үә тәсүәдду вүҗүүһ»**

*«Йә, Аллаһым! Бер төркем йөзләрнең агарып, икенче бер төркем йөзләрнең каралып калачак көнне минем йөземне дә агарт»*

## *5. <u>Уң кулны юганда укыла:</u>*

اللَّهُمَّ أَعْطِنِى كِتَابِى بِيَمِينِى وَ حَسِبْنِى حِسَبًا يَسِيرًا.

**«Аллаһүммә әгьтыйни китәәби бийәмиини үә хәәсибни хисәәбән йәсиира»**

*«Йә, Аллаһым! Китабымны уң яктан бир һәм хисабымны җиңеләйт»*



www.darul-kutub.com

## 6. <u>Сул кулны юганда укыла:</u>

اللَّهُمَّ لاَ تُعْطِنِي كِتَابِي بِشِمَالِي وَ لاَ مِنْ ظَهْرِي وَ لاَ تُحَاسِبْنِي حِسَابًا شَدِيدًا.

**«Аллаhүммә ләә түгътыйни китәәби бишимәәли үә ләә мин үәраaи заhри үә ләә түхәәсибни хисәәбәң шәдиидә»**

*«Йә, Аллаhым! Миңа китабымны сул ягымнан һәм артымнан бирмә, һәм миңа кырыс хисап насыйп итмә».*

## 7. <u>Башка мәсех кылганда укыла:</u>

اللَّهُمَّ أَظِلَّنِي تَحْتَ ظِلِّ عَرْشِكَ يَوْمَ لاَ ظِلَّ إِلاَّ ظِلُّكَ.

**«Аллаhүммә әзыйлләни тәхтә зыйлли гәршикә йәүмә ләә зыйллә илләә зыйллүк»**

*«Йә, Аллаhым! Гарш күләгәсеннән башка бернинди күләгә булмаган көнне миңа Гаршеңнең күләгәсендә басып торырга насыйп ит».*

## 8. <u>Колакларны мәсехләгәндә укыла:</u>

اللَّهُمَّ اجْعَلْنِي مِنْ الَّذِينَ يَسْتَمِعُونَ الْقَوْلَ فَيَتَّبِعُونِ أَحْسَنَهُ.

**«Аллаhүммә җгални минәл ләзиинә йәстәмигүүнәль каулә фәйәттәбигүүнә әхсәнәh»**

*«Йә, Аллаһым! Мине бары тик хак сүзләрне генә тыңлаган һәм иң күркәм нәрсәләр турында гына ишеткәннәрдән кыл».*

## 9. Муенны мәсехләгәндә укыла:

اللَّهُمَّ أَعْتِقْ رَقَبَتِي مِنَ النَّارِ وَ احْفَظْنِي مِنَ السَّلاَسِلِ وَ الأَغْلاَلِ.

**«Аллаһүммә әгътикъ ракабәти минә-н нәәри үәхфәзъни минә-с сәләәсили үәль агъләәл»**

*«Йә, Аллаһым! Муенымны утыңнан азат ит, чылбырлардан һәм муенчак тимерләреннән сакла».*

## 10. Аякларны юганда әйтелә торган дога:

اللَّهُمَّ ثبِّتْ قَدَمَيَّ عَلَى الصِّرَاطِ يَوْمَ تَزِلُّ فِيهِ الْأَقْدَامُ.

**«Аллаһүммә сәббит кадәмәййә галә-с сыйраатый йәүмә тәзиллү фииһи-ль әкъдәәм»**

*«Йә, Аллаһым! Аяклар тая торган көндә минем аякларыма нык булырга насыйп ит».*

www.darul-kutub.com

## Авырганда яки сызланганда укыла торган дога

Тирмизи Әнәс ибне Маликнең сүзләрен тапшырганча, Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи үәсәлләм әйтеп калдырган:

«Гәүдәңнең берәр урыны сызлаганда кулыңны шул урынга куй да шушы сүзләрне кабатла:

بِسْمِ اللهِ أَعُوذُ بِعِزَّةِ اللهِ وَ قُدْرَتِهِ مِنْ شَرِّ مَا أَجِدُ مِنْ وَجَعِى هَذَا.

**«Бисмилләәһи әгүүзү бигиззәтилләәһи үә кудьратиһи миң шәрри мәәә әҗидү миү үәҗәгый һәәзәә»**

*«Аллаһның исеме белән. Башыма килгән бу авыруның газабыннан Аллаһның гыйззәтенә һәм кодрәтенә сыенам».*

## Ахшам намазына азан ишеткәч укыла торган дога

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм ахшам азанын ишеткәч шушы доганы укый торган булган:

اللَّهُمَّ هَذَا إِقْبَالُ لَيْلِكَ وَ ادْبَارُ نَهَارِكَ وَ أَصْوَاتُ دُعَائِكَ فَاغْفِرْلِى.

**«Аллаhүммә hәәзәәә икъбәәлү ләйликә үә идбәәру нәhәәрикә үә әсъүәәту дүгәәәикә фәгъфир ли».**

*«Йә, Аллаhым! Бу азан төннең килүен hәм көннең төгәлләнүен белдереп чакыру тавышы. Мине гафу кыл!» («Әл-Әзкәр»: 82)*

## Ахшам намазыннан соң укыла торган дога

اللَّهُمَّ أَجِرْنِى مِنَ النَّارِ.

**«Аллаhүммә әҗирни минә-н нәәр».**

*«Аллаhым! Мине уттан коткар!» («Әл-Әзкәр»: 70)*

## Төчкергәч әйтелә торган дога

Әбү Һурайра тапшырганча, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаhу галәйhи үәсәлләм әйткән булган: «Арагыздан берегез төчкергәч, «Әлхәмдүлилләhи» (Аллаhка мактау) дисен, ә аның янын-



www.darulkutub.com

дагы кеше «Йәрхәмүкәллаһу» (Аллаһ Тәгалә сине ярлыкасын) дип әйтсен. Төчкергән кеше исә моңа җавап итеп дога кылсын:

يَهْدِيكُمُ اللّٰهُ وَ يُصْلِحُ بَالَكُمْ.

**«Йәһдиикүмуллаһу үә йүсълиху бәәләкүм».**

*«Аллаһ Тәгалә сезне һидаять юлына күндерсен һәм барча эшләрегезне тәртипкә салсын». (Бохари, «Әдәб»: 126)*

## Тау куышы кешеләре (әсъхәәбү кәһф) догасы

Яшь егетләр кяферләрдән куркып, мәгарәгә кереп качканнар һәм дога кылганнар:

رَبَّنَا اٰتِنَا مِنْ لَدُنْكَ رَحْمَةً وَ هَيِّئْ لَنَا مِنْ أَمْرِنَا رَشَدًا

**«Раббәнәәә әәтинәә мил ләдүңкә рахмәтәү үә һәййи-э ләнәә миң әмринәә рашәдәә».**

*«Әй, Раббыбыз! Үз тарафыңнан безгә рәхмәт бир һәм барча эшебезне хаклыкка сал, хаклык белән туры юлны табарбыз». («Кәһаф» сурәсе, 10 нчы аять)*

www.darulkutub.com

Нинди генә эш башлаганда да шушы доганы укырга тәкъдим ителә.

## Баш авыртканда укыла торган дога

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм башы авырткан кешеләргә шушы доганы укырга киңәш иткән:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ. بِسْمِ اللهِ الْكَرِيمِ وَ أَعُوذُ بِاللهِ الْعَظِيمِ مِنْ شَرِّ كُلِّ عِرْقٍ نَارٍ وَ مِنْ شَرِّ حَرِّ النَّارِ.

**«Бисмилләәһи-р рахмәәни-р рахиим. Бисмилләәһи-ль кәриим. Үә әгүүзү билләәһи-ль газыйм миң шәрри күлли гиркый нәәрин үә миң шәрри хәрри-н нәәр».**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән. Рахимле Бөек Аллаһ исеме белән. Һәр төрле авыруның зәхмәтеннән һәм Җәһәннәм утының газабыннан Бөек Аллаһы Тәгаләгә сыенам» («Мәуаһибу-л Ләдуннийййә»: 56).*

www.darul-kutub.com

## Бәлагә тарыган кешене күргәч әйтелә торган дога

Расүлүллаһ саләллаһу галәйһи үәсәләм: «Бәлагә тарыган кешене күргәч, әлеге доганы укыгыз. Ул очракта сезгә мондый бәла ирешмәс», – дигән.

الْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِى عَافَانِى مِمَّا ابْتَلاَكَ بِهِ وَ فَضَّلَنِى عَلَى كَثِيرٍ مِمَّنْ خَلَقَ تَفْضِيلاً.

**«Әлхәмдү лилләәһилләзии гәәфәәнии миммә бтәләәкә биһии үә фәддаләнии галәә кәсиирим миммән халәка тәфдыйләә».**

*«Сиңа килгән зарардан мине саклап калган, Үзе барлык китергәннәрдән миңа күбрәк өстенлек биргән күрсәткән Аллаһ Тәгаләгә мактау булсын!» (Тирмизи, «Дәгъват»: 3428).*

## Йөкташу хайваны яки машина сатып алгач укыла торган дога

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм йөк хайван сатып алган кешегә шушы доганы укырга тәкъдим иткән:



www.darul-kutub.com

اللَّهُمَّ إِنِّ أَسْأَلُكَ خَيْرَهُ وَ خَيرَ مَا جُبِلَ عَلَيْهِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهِ وَ شَرِّ مَا جُبِلَ عَلَيْهِ.

**«Аллаһүммә инниии әсьәлүкә хайраһүү үә хайра мәә җубилә галәйһи үә әгүүзү бикә миң шәрриһии үә шәрри мәә җубилә галәйһ».**

*«Йә, Аллаһым! Синнән моның хәерлесен, моның яратылмыштан ук булган хәерен сорыйм. Моның явызлыгыннан һәм яратылыштан ук булган зарарыннан Сиңа сыенам» (Нәвави, «Әл-Әзкәр»: 285).*

## Мәчеткә кергәндә укыла торган дога

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм мәчеткә кергәндә әлеге доганы укый торган булган:

أَعُوذُ باللهِ العَظيمِ وَبِوَجْهِهِ الكَرِيمِ وَسُلْطانِهِ القَديمِ مِنَ الشّيْطانِ الرَّجيمِ.الْحَمْدُ للهِ اللَّهمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلى مُحَمَّدٍ وَ عَلَى اَلِ محمَّدٍ.اللّهُمَّ اغْفِرْلِي ذُنُبِي وَ افْتَحْ لِي أَبْوابَ رَحْمَتِكَ.



www.darul-kutub.com

**«Әгүүзү билләәһи-ль газыйм үә биүәҗһиһи-ль кәрим үә сүльтаниһи-ль кадиим минә-ш шәйтаани-р раҗиим. Әлхәмдү лилләһ. Аллаһүммә салли үә сәллим галәә Мүхаммәдиү үә галәәә әәли Мүхәммәд. Аллаһүммә гъфир лии зүнүүбии үәфтәх ли әбүәәбә рахмәтик».**

*«Ләгънәт төшкән шайтаннан Аллаһ Раббымның чиксез көч-куәтенә сыенам. Аллаһ Тәгаләгә мактау булсын! Йә, Аллаһым! Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның кавеменә рәхмәт һәм сәлам кыл. Йә, Аллаһым! Гөнаһларымны гафу ит, мәрхәмәт-шәфкать ишекләреңне минем өчен ач!» («Әл-Әзкәр»: 32).*

## Мәчеттән чыкканда әйтелә торган дога

Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм мәчеттән чыкканда шушы доганы укый торган булган:

اللَّهُمَّ إِنِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ إِبْلِيسَ وَ جُنُودِهِ.

**«Аллаһүммә иннии әгүүзү бикә мин Иблиисә үә җүнүүдиһ».**

*«Йә, Аллаһым! Иблистән һәм аның гаскәреннән Сиңа гына сыенам!» («Әл-Әзкәр»: 33).*

www.darul-kutub.com

## Җеназа күргәндә укыла торган дога

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм берәр җеназа күргәндә шушы доганы укый торган булган:

لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ الْحَيُّ الَّذِى لاَ يَمُوتُ

**«Ләәәә иләәһә илләәллаһуль хәййүлләзии ләә йәмүүт».**

*«Мәңге Бар булган һәм беркайчан да үлми торган Аллаһтан башка илаһ юк» («Әл-Әзкәр»: 146).*

## Саранлыктан котылу өчен кылына торган дога

Әлеге доганы да Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм укырга тәкъдим иткән:

اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْبُخْلِ وَ الْكَسْلِ وَ أَرْزَلِ الْعُمْرِ وَ عَذَابِ الْقَبْرِ وَ فِتْنَةِ الْمَحْيَا وَ الْمَمَاتِ.

**«Аллаһүммә инниии әгүүзү бикә минә-ль бүхъли үә-ль кәсәли үә әрзәли-ль гумүри үә газәәби-ль кабри үә фитнәти-ль мәхйәә үә-ль мәмәәт».**



www.darul-kutub.com

*«Йә, Аллаһым! Саранлыктан, ялкаулыктан, хәлсезлектә уткән гомердән, кабер газабыннан, яшәеш һәм үлемнең фетнәсеннән Сиңа сыенам» (Мөслим: 75).*

## Җенси мөнәсәбәткә кергәнче укыла торган дога

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм әйткән: «Әгәр арагыздан берегез, хатынысыз белән кушылганчы, шушы доганы укыса һәм әлеге кушылу нәтиҗәсендә бала туса, ул балага шайтан мәңге зарар итә алмас»:

بِسْمِ اللهِ اللَّهُمَّ جَنِّبْنَا الشَّيْطَانَ وَ جَنِّبِ الشَّيْطَانَ مَا رَزَقْتَنَا

**«Бисмилләәһи Аллаһүммә җәннибнә-ш шәйтаанә үә җәнниби-ш шәйтаанә мәә разәкътәнәә».**

*«Аллаһның исеме белән. Йә, Раббым! Безне шайтаннан ерак кыл һәм безгә насыйп иткәнеңнән дә шайтанны ерак кыл» (Мөслим: 4/155).*

www.darul-kutub.com

## Җомга иртәсендә укыла торган дога

Аллаh Расүле салләллаhу галәйhи үәсәлләм җомга көне иртәләрендә әлеге доганы укый торган булган:

أَسْتَغْفِرُ اللهَ الَّذِى لاَ إِلَهَ إِلاَّ هُوَ الْحَىَّ الْقَيُّمَ وَ أَتُوبُ إِلَّيْهِ .

**«Әстәгъфируллаhә ллэзии ләәә иләәhә илләә hүүәль хәййү-ль каййүүмә үә әтүүб иләйhи».**

*«Аннан башка hичбер илаh булмаган тере hәм даими бар булган Аллаh Тәгаләдән гафу сорыйм hәм тәүбә итәм» («Әл-Әзкәр»: 80).*

## Дәҗҗал фетнәсеннән саклану өчен укыла торган дога

Бу доганы Аллаh Расүле салләллаhу галәйhи үәсәлләм еш укый торган булган:

اللَّهُمَّ إِنِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابِ جَهَنَّمَ وَ مِنْ عَذَابِ الْقَبْرِ
وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْمَسِيحِ الدَّجَّالِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ
فِتْنَةِ الْمَحْيَا وَ الْمَمَاتِ.

www.darul-kutub.com

**«Аллаһүммә инниии әгүүзү бикә мин газәәби җәһәннәмә үә мин газәәби-ль кабьри үә әгүүзү бикә миң фитнәти-ль мәсиихи-д дәҗҗәәли үә әгүүзү бикә миң фитнәти-ль мәхьйәә үә-ль мәмәәт».**

*«Әй, Аллаһым! Җәһәннәм газабыннан, кабер газабыннан, ялганчы Мәсихның (Дәҗҗалның) фетнәсеннән, үлемнең һәм тормышының фетнәсеннән Сиңа сыенам!» (Нәвави, «Әл-Әзкәр»: 28).*

## Җир тетрәгәндә укыла торган дога

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләм җир тетрәгәндә, давыл чыкканда, су ташкынына юлыкканда бу доганы укырга тәкъдим иткән:

اللَّهُمَّ احْفَظْنِي مِنْ بَيْنِ يَدَّىَّ وَ مِنْ خَلْفِي وَ عَنْ
يَمِينِي وَ عَنْ شِمَالِي وَ مِنْ فَوْقِي وَ أَعُوذُ بِعَظَمَتِكَ
أَنْ أُغْتَالَ مِنْ تَحْتِي.

**«Аллаһүммә хфәзъниии мим бәйни йәдәййә үә мин хальфи үә гән йәмииини үә гәң шимәәли үә миң фәүкый үә әгүүзү бигазамәтикә ән үгътәәлә миң тәхти».**

*«Йә, Аллаһым! Алдымнан һәм артымнан, уңымнан һәм сулымнан шулай ук өстемнән миңа килергә мөмкин барча афәтләрдән сакла! Синең бөеклегеңә астымнан куптарылуымнан сыгынам» (Әбү Давуд: 1177)*

## Диндә нык булу өчен укыла торган дога

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм еш кына шушы доганы укый торган булган:

يَا مُقَلِّبَ الْقُلُوبِ ثَبِّتْ قَلْبِي عَلَى دِينِكَ.

**«Йәә мүкаллибә-ль кулүүби сәббит кальбии галәә дииник».**

*«Әй, йөрәкләрне Үзе теләгән шәкелгә кертүче Аллаһым! Минем йөрәгемне Үзеңнең хак динеңә юнәлт!» («Тухфәтү-л Ахвәзү»: 9/504).*

## Теш сызлаганда укыла торган дога

Әсъхәәб-е Кирамнан (данлыклы, хөрмәтле сәхабәләр) Габдуллаһ ибне

www.darulkutub.com

Рәвахә (Аллаһ аннан риза булсын!) бер көнне Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләмгә теше сызлаганы турында сөйләгән. Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи үәсәлләм үзенең кулын Хәзрәти Габдуллаһның теше сызлаган яңагына куеп шушы доганы укыган:

اللَّهُمَّ أَذْهِبْ عَنْهُ سَوءَ مَا يَجِدُ وَ فَحْشَهُ بِدَعْوَةِ نَبِيِّكَ الْمَكِينِ الْمُبَارَكِ عِنْدَكَ

**«Аллаһүммә әзһиб ганһү сүү-ә мәә йәҗидү үә фәхшәһүү бидәгьүәти нәбиййикә-ль мәкиини-ль мүбәәраки гиңдәк».**

*«Йә, Аллаһым! Мөбәрак һәм мөхтәрәм пәйгамбәребезгә Син иңдергән догасы ярдәмендә тешемдәге шушы авыруны/сызлауны бетер!» («Мәвәхибу-л Ләдуннийя»: 75).*

## Куллар юганда укыла торган дога

Әбү Һүрайра сөйләп калдырган: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм

ашаганнан соң кулларны юганда әлеге доганы кылган:

الْحَمْدُ لله الَّذِى يُطْعِمُ وَ لاَ يُطْعَمُ مَنَّ عَلَيْنَا فَهَدَانَا
وَ أَطْعَمَنَا وَ سَقَانَا.

**«Әлхәмду лилләәһи лләзии йүтъгиму үә ләә йүтъгәму мәннә галәйнәә фәһәдәәнәә үә әтъгәмәнәә үә сәкаанәә».**

*«Туендырган, ләкин туйдырылмаган Аллаһка мактау булсын. Ул безне мәрхәмәте белән туры юлга кундерде, карыныбызны туендырды, сусавыбызны басырды» (Хаким, «Әл-Мустәдрәк»: 1/456).*

## Кием кигәндә укыла торган дога

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләм кием кигәндә бу доганы укырга кушкан:

الْحَمْدُ لله الَّذِى كَسَانِى هَذَا وَ رَزَقَنِيهِ مِنْ غَيْرِ
حَوْلٍ مِنِّى وَ لاَ قُوَّةٍ.

**«Әлхәмду лилләһи лләзии кәсәәнии һәәзәә үә разәканииһии мин гайри хәүлим минни үә ләә куүәһ».**

*«Шушы киемне миңа насыйп иткән һәм шуның белән мине киендергән Аллаһ Тәгаләгә мактаулар булсын! Үземнең генә аңа көч-куәтем җитмәс иде» (Нәвави, «Әл-Әзкәр»: 22).*

## Өйдән чыкканда укыла торган дога

Әнәс ибне Малик тапшырганча, Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм әйткән: «Өйдән чыкканда шушы доганы укыган кеше Аллаһ тарафыннан сак астына алыныр, хәтта шайтан да ул кешедән читләшер»:

بِسْمِ اللهِ تَوَكَّلْتُ عَلى اللهِ وَلاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاّ بِاللهِ.

**«Бисмилләәһи тәүәккәлтү галәллаһ. Ләә хәүлә үә ләә куүәтә илләә билләһ».**

*«Аллаһның исеме белән, Аңа тәвәккәл кылдым, куәт һәм көч бер Аллаһтан» (Тирмизи, «Дәгъват»: 34).*

www.darul-kutub.com

# Өйгә кергәндә укыла торган дога

Әбү Малик әл-Әшгари (Аллаһ аннан риза булсын!) Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләмнең әйткәннәрен тапшырган: «Кеше өенә кергәндә шушы доганы укысын һәм аннан соң өендәге кешеләргә сәлам бирсен»:

اللَّهُمَّ إِنِّ أَسْأَلُكَ خَيرَ الْمَوْلَجِ وَ خَيرَ الْمَخْرَجِ بِسْمِ اللهِ
وَلَجْنَا وَبِسْمِ اللهِ خَرَجْنَا وَعَلىَ رَبِّنَا تَوَكَّلْنَا.

**«Аллаһүммә иннииии әсьәлүкә хайра-ль мәүләҗи үә хайра-ль мәхъраҗи бисмилләәһи үәләҗнәә үә бисмилләәһи хараҗнәә үә галәллаһи раббинә тәүәккәлнәә».**

*«Аллаһым! Мин керәсе һәм чыгасы урыннарны хәерле ит. Аллаһымның исеме белән кердем, Аллаһымның исеме белән чыгам. Аңа гына тәвәккәл кылам» (Мөслим, «Әшрибә»: 2018)*

www.darulkutub.com

## Бала сорап укыла торган дога

Алга таба китерелгән дога аятьләрен пәйгамбәрләр дога итеп укый торган булган:

فَهَبْ لِى مِنْ لَدُنْكَ وَلِيًّا * يَرِثُنِى وَ يَرِثُ مِنْ اٰلِ يَعْقُوبَ.

**«Фәһәб ли мил ләдүңкә үәлиййәә. Йәрисунии үә йәрису мин әәли Йагъкуб».**

*«Үзеңнең фазылыңнан миңа бер изге угыл бир! Ул угыл миңа варис булыр һәм Ягъкуб балаларына варис булыр» («Мәрьям» сүрәсе, 5-6 аятьләр).*

## Яңа өйләнешүчеләргә укыла торган дога

Әбү Һүрайра (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырган: Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм яңа өйләнешүчеләргә укыган дога:

بَارَكَ اللّٰهُ لَكَ وَ بَارَكَ عَلَيْكَ وَ جَمَعَ بَيْنَكُمَا فِى خَيْرٍ.

**«Бәәракәллаһу ләкә үә бәәракә галәйкә үә җәмәга бәйнәкүмәә фии хайр».**

www.darul-kutub.com

*«Аллаһ Тәгалә сезгә бәрәкәтен бирсен, Үзенең ярдәмен яудырсын һәм бәхет белән яшәргә насыйп итсен!» (Әбү Дауд, 2130).*

## Әюб галәйһиссәламнең догалары

Әлеге догалар Коръән Кәримдә өйрәтелгән догалардан берничәсе. Аларны авыру чагында Әюб галәйһиссәлам укый торган булган:

إِنِّي * مَسَّنِيَ الضُّرُّ وَ أَنْتَ اَحْرَمُ الرَّاحِمِينَ

**«Иннии мәссәнийә-д дурру үә әңтә әрхәмү-р раахимиин».**

*«Мине сырхау һәм катылык тотты, Син рәхмәт итүчеләрнең иң рәхимлесе, миңа да рәхмәт ит» («Әнбия» сүрәсе, 83 нче аять).*

Әюб галәйһиссәлам, үзенең авыр хәлен белдереп, тагын да дога кылган:

---

*1 Аять эчендә «әнни» дип укыла. Ләкин «әннә»дән башланганда, гарәп грамматикасы кагыйдәләре буенча «инни» буларак укыла.*



www.darulkutub.com

إِنِّي مَسَّنِيَ الشَّيْطَانُ بِنُصْبٍ وَ عَذَابٍ.

**«Иннии мәссәнийә-ш шәйтаану бинүсубиү үә газәәб».**

*«Мине шайтан авырлык һәм каты мәшәкать белән тотты» («Сад» сүрәсе, 41 нче аять)*

## Азаннан соң укыла торган дога

Хәзрәти Җәбир (Аллаһ аннан риза булсын!) Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләмнең әйткәннәрен тапшырган: «Азан ишеткәч, шушы доганы укыган кешегә кыямәт көнендә шәфәгатем вәҗиб булыр:

اللّٰهُمَّ رَبَّ هَذِهِ الدَّعْوَةِ التّامَّةِ وَالصَّلاَةِ القَائِمَةِ آتِ مُحَمَّداً ن الوَسيلةَ وَالْفَضِيلَةَ وَابْعَثْهُ مَقَاماً مَحْمُوداً ن الَّذِي وَعَدْتَهُ.

**«Аллаһүммә Раббә һазиһи-д дәгьүәти-т тәәәммәти үә-с саләәти-л кааамимәһ. Әәти Мүхәммәдәни-ль үәсиләтә үә-ль фәдыйләтә үәд-дәраҗәтә-ль-гәәлийәтә-р-рафииғаһ. Үәбгасһү мәкаамәм-мәхмүүдәни-лләзии үәгадтәһ».**

www.darul-kutub.com

*«Аллаһым! Шушы барлык чакыруның һәм кылына торган намазның Раббысы! Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләмгә ярдәмне һәм артылыкны, югары һәм өстен булган дәрәҗәне, фазыйләтне бир. Аны үзенә вәгъдә ит. Мәхмүд дәрәҗәләренә ирештер» (Бохари, Азан: 2/77).*

## Көймәгә утырганда укыла торган дога

Әлеге дога Коръән Кәримдә өйрәтелгән. Аны хәзрәти Нух галәйһиссәлам көймәсенә менгәндә укыган:

بِسْمِ اللهِ مَجْرَيْهَا وَ مُرْسَيْهَا ۚ إِنَّ رَبِّى لَغَفُورٌ رَحِيمٌ.

**«Бисмилләәһи мәҗрәәһәә үә мүрсәәһәә. Иннә раббии ләгафүүру-р рахиим».**

*«Бу көймәнең йөреше һәм туктавы Аллаһ теләге белән булыр, дип әйтегез! Һичшиксез, минем Раббым мөэминнәрне ярлыкучы һәм рәхмәт итүче» («Һуд» сүрәсе, 41 нче аять).*

www.darul-kutub.com

## Кияү белән кәләш бүлмәсенә кергән ир укырга тиеш дога

Гамр ибни Шөгайб Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләмнең әйткәннәрен тапшырган: «Берәрегез өйләнгән вакытта шушы доганы укысын:

اللَّهُمَّ إِنِّ أَسْأَلُكَ خَيرُهَا وَ خَيرُ مَا جَبَلْتَهَا وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا وَ شَرِّ مَا جَبَلْتَهَا عَلَيْهِ.

**«Аллааһүммә инниии әсь-әлүкә хайраһәә үә хайра мәә җәбәлтәһәә үә әгүүзү бикә миң шәрриһәә үә шәрри мә җәбәлтәһәә галәйһ».**

*«Аллаһым! Хакыйкатьтә мин Сине аның хәерле булуын һәм Син аны бар иткәнеңнең хәерле булуын сорыйм. Сиңа аның явызлыгыннан һәм аны бар иткәнеңнең явызлыгыннан сыгынам» (Әбү Давуд: 2/248).*

## Сугышта дошманны җиңү өчен укыла торган дога

Бу доганы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләм үзе укый торган булган:

اللَّهُمَّ مُنْزِلَ الْكِتَابِ سَرِيعَ الْحِسَابِ, اِهْزِمِ الْأَحْزَابَ .
اللَّهُمَّ اهْزِمْهُمْ وَ زَلْزِلْهُمْ.

**«Аллааhүммә мүнзилә-л китәәби сәриига-ль хисәәб, иhзими-ль әхзәәб. Аллааhүммә hзимhүм үә зәлзилhүм».**

*«Олуг китапны иңдергән һәм хисап кылучы Раббым, бу хизебләрне чәлперәмә ит. Йә, Раббым, аларны юкка чыгар һәм тетрәндер» (Нәвави, «Әл-Әзкәр»: 188).*

## Авырудан сәламәтләнү өчен укыла торган дога

Әлеге доганы Мөхәммәд салләллаhу галәйһи үәсәлләм укырга тәкъдим иткән:

اللَّهُمَّ عَافِنِي فِي جَسَدِي وَ عَافِنِي فِي بَصَرِي وَ اجْعَلْهُ
الْوَارِثَ مِنِّي . لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ الْحَلِيمُ الْكَرِيمُ سُبْحَانَ اللهِ رَبِّ
الْعَرْشِ الْعَظِيمِ وَ الْحَمْدُ لله رَبِّ الْعَالَمِينَ.

**«Аллааhүммә гәәфини фии җәсәдии үә гәәфинии фии бәсарии үәҗгалhү-ль үәәрисә миннии. Ләәә иләәhә илләәллаhу-ль хәлииму-ль кәрииму сүбхәәнәллааhи**

**рабби-ль гәрши-ль гәзыйми үә-ль хәмдү лилләәһи рабби-ль гәәләмиин».**

*«Йә, Аллаһым! Минем тәнемне сәламәтләндер, куру сәләтемә дә шифа бир. Куру сәләтемне миңа варис ит. Рәхимле һәм киң күңелле Аллаһтан башка һичбер иләһ юк. Бөек Гарешнең Раббысы булган Аллаһ Тәгаләне барлык кимчелекләрдән дә пакь дип таныйм. Барча мактаулар галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка гына!» («Тухфәту-л Ахвәзи»: 9/451).*

## Бәдрәфкә кергәндә укыла торган дога

Әнәс (Аллаһ аннан риза булсын!) риваять иткән: Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм бәдрәфкә кергәндә бу доганы укый торган булган:

بِسْمِ اللهِ اللّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْخُبْثِ وَالْخَبائِثِ.

**«Бисмилләәһи, Аллааһүммә инниии әгүүзү бикә миңә-ль хубүси үә-ль хабәәәис».**

*«Аллаһның исеме белән. Йә, Аллаһым! Әлбәттә, мин әшәкелек һәм яманлык итүче ир һәм хатын җенесендә булган шайтаннадан Сиңа сыгынам» (Бохари, «Дәгъват»: 54).*

## Бәдрәфтән чыкканда укыла торган дога

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм бәдрәфтән чыкканда шушы доганы укый торган булган:

الْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِى أَذْهَبَ عَنِّى الْأَذَى وَ عَافَانِى.

**«Әлхәмдү лилләәһилләзиии әзһәбә гәнни-ль әзәә үә гәәфәәни».**

*«Минем газаплануларыма чик куйган һәм мине сәламәтләндергән Аллаһка мактаулар булсын» (Ибни Мәҗә, «Тәһарәт»: 301).*

## Һидаятькә һәм тәкъвалыкка ирешү өчен кылына торган дога

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм еш кына әлеге доганы укый торган булган:

اللّٰهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ الْهُدَى وَ التُّقَى وَ الْعَفَافَ وَ الْغِنَى .

www.darul-kutub.com

**«Аллааһүммә иннии әсь-әлүкәль һүдәә үә-т түкаа үә-ль гафәәфә үә-ль гыйнәә».**

*«Аллаһым! Синнән һидаять, тәкъвалык, гыйффәт һәм байлык сорыйм» (Мөслим, «Зикир»: 18).*

## Истихарә догасы

Бу доганы Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм өйрәткән:

اللّهُمَّ إِنِّي أَسْتَخِيرُكَ بِعِلْمِكَ وَأَسْتَقْدِرُكَ بِقُدْرَتِكَ
وَأَسْأَلُكَ مِنْ فَضْلِكَ العَظِيمِ فَإِنَّكَ تَقْدِرُ وَلاَ أَقْدِرُ
وَتَعْلَمُ وَلاَ أَعْلَمُ وَأَنْتَ عَلاَّمُ الغُيُوبِ. اللّهُمَّ إِنْ كُنْتَ
تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الأَمْرَخَيْرٌ لِي فِي دِينِي وَمَعاشِي وَعاقِبَةِ
أَمْرِي عَاجِلِهِ وَ اَجِلِهِ فَاقْدُرْهُ لِي وَيَسِّرْهُ لِي ثُمَّ بَارِكْ لِي فِيهِ
وَإِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذا الأَمْرَ شَرٌ لِي فِي دِينِي وَمَعَاشِي
وَعَاقِبَةِ أَمْرِي عَاجِلِ أَمْرِي وَ اَجِلِهِ فَاصْرِفْهُ عَنِّي وَاصْرِفْنِي
عَنْهُ وَاقْدُرْ لِيَ الخَيْرُ حَيْثُ كَانَ ثُمَّ أَرْضِنِي بِهِ.

**«Аллааһүммә иннии әстәхыйрукә бигыйль-микә үә әстәкъдирукә бикудьратикә үә әсь-әлүкә**

www.darul-kutub.com

**миң фәдъликәль газыйм. Фәиннәкә такъдиру үә ләә әкъдиру үә тәгьләмү үә ләәә әгьләмү үә әңтә галләәмү-ль гуйүүб. Аллааһүммә иң күңтә тәгьләмү әннә һәәзә-ль әмра хайрул лии фии диинии үә мәгәәшии үә гәәкыйбәти әмрии гәәҗилиһии үә әәҗилиһии фәкъдүрһү лии үә йәссирһү лии сүммә бәәрикь лии фииһ. Үә иң күңтә тәгьләмү әннә һәәзә-ль әмра шәррул ли фии диинии үә мәгәәшии үә гәәкыйбәти әмрии гәәҗили әмрии үә әәҗилиһии фәсърифһү гәннии үәсърифни гәнһү фәкъдур лийә-ль хайра хәйсү кәәнә сүммә әрдыйнии биһи».**

*«Йә, Раббым! Үзеңнең гыйлемең белән, кодрәтең белән миңа ярдәм итүеңне сорыйм. Миңа Үзеңнең чиксез шәфәгатеңне кылсаң иде. Син һәрбер теләгәнеңне кыла аласың, ә мин кыла алмыйм. Син һәрбер нәрсәне беләсең, ә мин белмим. Син барча беленмәгәнне дә беләсең. Йә, Раббым! Әгәр шушы эш динемә, тормышыма, эшләремә файда китерерлек булса, аны миңа насыйп ит, җиңеләйт һәм Үзеңнең шәфәгатеңне кыл. Әгәр дә бу эш динемә, тормышыма, эшләремә зарар китерә торган булса, аны миннән ерак кыл, аңардан мине коткар, миңа рәхмәтеңне бүләк ит, миңа бәхет бир, мине ул бәхет белән канәгатьләндерсәң иде» (Бохари, «Дәгъвәт»: 1/155).*

Бу доганы укыгач, теләгәнеңне сорарга кирәк.

## Итәгатьле мөселманнар догасы

Әлеге дога Коръән Кәримдә өйрәтелгән һәм аны итәгатьле мөселманнар кыла торган булган:

رَبَّنَا إِنَّنَا سَمِعْنَا مُنَادِيًا يُنَادِى لِلْإِيمَانِ أَنْ آمِنُوا بِرَبِّكُمْ فَآمَنَّا ۚ رَبَّنَا فَاغْفِرْ لَنَا ذُنُوبَنَا وَكَفِّرْ عَنَّا سَيِّئَاتِنَا وَتَوَفَّنَا مَعَ الْأَبْرَارِ ۚ* رَبَّنَا وَآتِنَا مَا وَعَدْتَنَا عَلَى رُسُلِكَ وَلَا تُخْزِنَا يَوْمَ الْقِيَامَةِ ۗ إِنَّكَ لَا تُخْلِفُ الْمِيعَادَ.

**«Раббәнәәә иннәнәә сәмигьнәә мүнәәдийййәй йүнәәдии лиль ииމәәни ән әәминүү бираббикүм фәәәмәннәә раббәнәә фәгъфир ләнәә зүнүүбәнәә үә кәффир гәннәә сәййиәәтинәә үә тәүәффәнәә мәгәль әбраар. Раббәнәә үә әәтинәә мәә үәгадьтәнәә галәә русүликә үә ләә түхъзинәә йәүмәл кыйәәмәһ. Иннәкә ләә түхълифү-ль миигәәд».**

*«Йә, Раббыбыз! Шиксез, иманга чакыручы сүзләрен*

*ишеттек: «Раббыгызга ышаныгыз», – дип чакыруына, әлбәттә, ышандык. Әй, Раббыбыз, гөнаһларыбызны ярлыка һәм яхшы эшләребезне начар эшләребезгә кәффарәт ит һәм безне изге кешеләр белән бергә кавышкан хәлдә вафат ит! Әй, Раббыбыз! Расулләрең аша безгә вәгъдә иткән җәннәтне дә бир һәм кыямәт көнне безне хур кылма! Син, әлбәттә, вәгъдәңне бозмыйсың» («Әлү Гыймран» сурәсе, 193-194 нче яатьләр).*

## Игелекле гамәлләргәирешү өчен кылына торган дога

Коръән Кәримдә игелекле гамәлләргә ирешү өчен кылына торган дога да өйрәтелгән:

رَبِّ أَوْزِعْنِي أَنْ أَشْكُرَ نِعْمَتَكَ الَّتِي أَنْعَمْتَ عَلَيَّ وَعَلَى وَالِدَيَّ وَأَنْ أَعْمَلَ صَالِحًا تَرْضَيهُ وَأَصْلِحْ لِي فِي ذُرِّيَّتِي ۚ إِنِّي تُبْتُ إِلَيْكَ وَإِنِّي مِنَ الْمُسْلِمِينَ.

**«Рабби әүзигьнии ән әшкүра нигьмәтәкәл ләтиии әнгәмтә гәләййә үә гәләә үәәлидәййә үәән әгьмәлә**

**саалихәң тәрдааһү үә әсълих лии фии зүррийәтии. Иннии түбтү иләәйкә үә иннии миңәль мүслимиин».**

*«Әй, Раббым, миңа өлеш бирсәң иде, үземә һәм ата-анама биргән һидаять вә ислам нигъмәтенә шөкер итүне насыйп ит. Әй, Раббым, балаларымны да ислах ит, бар да мөэмин булсыннар. Әй, Раббым, мин Сиңа кайттым һәм, мөселманнардан булып, һәр әмереңә итәгать иттем» («Әхкаф» сурәсе, 15 нче аять).*

## Кадер-хөрмәткә һәм дәрәҗәләргә ирешү өчен укыла торган дога

Бу дога да Коръән Кәримдә китерелгән һәм кадер-хөрмәткә, дәрәҗәләргә ирешү өчен укыла:

تُعِزُّ مَنْ تَشَاءُ وَتُذِلُّ مَنْ تَشَاءُ* قَدْ جَعَلَ اللهُ لِكُلِّ شَيْءٍ قَدِرًا.

**«Түгиззү мәң тәшәәә-ү үә түзиллү мәң тәшәәә-ү. Кадь җәгәләллаһу ликүлли шәй-иң кадьра».**

*«Теләгән бәндәңне Коръән белән гамәл кылдырып хөрмәтле итәсең, һәм теләгән бәндәңне Коръәннән*

*гафил кылып хур итәсең». «Әлбәттә, Аллаһ һәрнәрсәгә чик-үлчәү куйды» («Әлу Гыймран» сурәсе, 26 нчы аять; «Талак» сурәсе, 3 нче аять).*

## Кабер газабыннан котылу өчен укыла торган дога

Бу дога Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм өйрәтеп калдырган догаларның берсе:

اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابٍ فِي النَّارِ وَ
عَذَابٍ فِي الْقَبْرِ.

**«Аллааһүммә инниии әгүүзү бикә мин гәзәәбиң фин нәәри үә гәзәәбиң фил кабьр».**

*«Аллаһым! Мин Сиңа сыенам җәһәннәм утыннан һәм кабер газабыннан» (Мөслим: 8/82).*

## Кадер кичәсендә укыла торган дога

Хәзрәти Гаишә (Аллаһ аннан риза булсын!) сөйләп калдырган: «Йә, Расүл-



www.darul-kutub.com

үллаһ, Кадер кичәсенең кайсы кичә икәнен белсәк, ул кичне ни дип әйтергә кирәк?» дип сораганыма Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм бу доганы укырга кушты:

اللَّهُمَّ إِنَّكَ عَفُوٌّ كَرِيمٌ تُحِبُّ الْعَفْوَ فَاعْفُ عَنِّى.

**«Аллааһүммә иннәкә гәфүвүң кәриимүң түхиббүль гәфүә фәгьфү гәнни».**

*«Йә, Аллаһым, һичшиксез, Син гафу кылучы, Син икрам иясе, гафу итәргә яратасың, гафу ит мине» (Тирмизи, «Дәгъвәт»: 85).*

## Куркыныч төш күргәч укыла торган дога

Әлеге доганы Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм өйрәткән:

أَعوذُ بِكَلِماتِ اللهِ التَّامَّاتِ مِن غَضَبِهِ وَعِقَابِهِ وَشَرِّ عِبادِهِ وَمِنْ هَمَزاتِ الشَّيَاطِينِ وَأَنْ يَحْضُرُونِ.

www.darul-kutub.com

**«Әгүүзү бикәлимәәтил ләәһит тәәәммәәти мин гадабиһии үә гикаабиһии үә шәрри гибәәдиһии үә миң һәмәзәәтиш шәйәәтыйни үә әй йәхдуруун».**

*«Ачуыннан, газабыннан, колларының явызлыгыннан, шайтан вәсвәсәсеннән, аларның миңа килуләреннән Аллаһның камил кәлимәләренә (сүзләренә) сыенам» (Нәвәви, «Әл-Әзкәр»: 92).*

## Әхлакны дөресләү өчен кылына торган дога

Бу доганы Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм укый торган булган:

اللَّهُمَّ إِنِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ مَنْكَرَاتِ الْأَخْلاَقِ
وَ الِأَعْمَالِ وَ الِأَهْوَالِ.

**«Аллааһүммә инниии әгүүзү бикә мим мүңкәраатиль әхъләәкый үәль әгьмәәли үәль әһвәәл».**

*«Аллаһым, әхлакның, эшләрнең начарыннан Сиңа сыгынам» (Нәвави, «Рийадус- Салихин»: 1497).*

www.darul-kutub.com

## Корбан чалучы кеше әйтә торган дога

Корбан чалучы кеше, корбан хайванын бугазлаганчы, тәкбир әйтергә тиеш:

اللّٰهُ أَكْبَرُ اللّٰهُ أَكْبَرُ. لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللّٰهُ وَ اللّٰهُ أَكْبَرُ
اللّٰهُ أَكْبَرُ وَ لِلّٰهِ الْحَمْدُ.

**«Аллааһу әкбәр. Аллааһу әкбәр. Ләәә иләәһә илләллааһу ўаллааһу әкбәр. Аллааһу әкбәр ўә лилләәһиль хәмдү».**

*«Аллаһ бөек. Аллаһ бөек. Аллаһтан башка иләһ юк, һәм Аллаһ бөек. Аллаһ бөек һәм барча мактаулар Аллаһ Тәгаләгә генә».*

## Корбан чалганчы аягүрә басып укыла торган дога

Бу дога Коръән Кәримдә китерелгән һәм аны корбан чалганчы укырга кирәк:

إِنِّ وَجَّهْتُ وَجْهِىَ لِلَّذِى فَطَرَ السَّمَوَاتِ وَ الْأَرْضَ حَنِيفًا
وَ مَا أَنَا مِنَ الْمُشْرِكِينَ ج

www.darul-kutub.com

**«Иннии үәҗҗәһтү үәҗһийә лилләзии фәтарас сәмәәүәәти үәль әрда хәниифәү үә мәәә әнә минәль мүшрикиин».**

*«Батылдан хакка авышканым хәлдә җир һәм күкләрне төзүче Аллаһка йөземне юнәлдердем һәм мин Аллаһка һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылучы түгелмен» («Әнгам» сурәсе, 79 нчы аять).*

Корбан чалганнан соң ике рәкәгать намаз уку сөннәт була. Намаздан соң шушы доганы укырга кирәк:

إِنَّ صَلَاتِي وَنُسُكِي وَمَحْيَايَ وَمَمَاتِي لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ .

**«Иннә саләәтии үә нүсүкии мәхьйәәйә үә мәмәәтии лилләәһи раббиль гәәләмиин».**

*«Укыган намазларым һәм бугазлаган корбаннарым фәкать Аллаһ ризалыгы өчен генә эшләнә һәм тере булуым да, үлүем дә бөтен галәмнәрне тәрбия кылучы Аллаһ Тәгалә эше» («Әнгам» сурәсе, 162 нче аять).*

www.darulkutub.com

# Намаз эчендә укыла торган кайбер сүрәләр

## *«Фатиха» сүрәсе*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۙ *الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۙ * مَالِكِ يَوْمِ
الدِّينِ ۗ* إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ ۗ * اهْدِنَا الصِّرَاطَ
الْمُسْتَقِيمَ ۙ * صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ ۙ غَيْرِ
الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلَا الضَّآلِّينَ.

**«Бисмилләәһи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Әлхәмдү лилләәһи раббиль гәәләмииң. Әр-рахмәәнир-рахиим. Мәәлики йәүмиддиин. Иййәәкә нәгьбүдү үә иййәәкә нәстәгиин. Иһдинәс сыйрааталь мүстәкыйм. Сыйраатал ләзиинә әнгәмтә гәләйһим гайриль мәгъдууби гәләйһим үәләәд дааааллиин. (Әмин)».**

*«Шәфкатьле, рәхимле Аллаһ исеме белән башлыйм эшемне.*

*Чын мактау галәмнәрне, барлык мәхлукларны тәрбияләүче Аллаһ Тәгаләгә тиешле. Аллаһ Тәгалә бу дөньяда барча кешеләргә мәрхәмәтле, ягъни*

*мөэминнәргә дә, кяферләргә дә нигъмәтләрен бирә, әмма Ахирәттә мөэмин бәндәләренә генә бирәчәк. Аллаһ Тәгалә гаделлек белән хөкем итүче, кыямәт көненең патшасы. Әй, тәрбиячебез Аллаһ! Без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм һәр эшебездә Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Әй, тәрбиячебез Аллаһ! Безне тугры юлга күндер! Ул юлны Син әүвәлгеләргә ингам итеп бирдең, безне Синең ачуың төшкән һәм адашкан кешеләрнең юлыннан башка юлга күндер. («Фатиха» сүрәсе, 1-7 нче аятьләр).*

## *«Аятель Көрси»*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
اللّٰهُ لَاَ إِلٰهَ إِلَّا هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ لَا تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلَا نَوْمٌ
لَهُ مَا فِي السَّمٰوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ مَنْ ذَا الَّذِى
يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلَّا بِإِذْنِهِ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَمَا
خَلْفَهُمْ وَلَا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلَّا بِمَا شَاءَ
وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمٰوَاتِ وَالْأَرْضَ وَلَا يَئُودُهُ حِفْظُهُمَا
وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ.

www.darul-kutub.com

**«Бисмилләәһир рахмәәни-р рахиим.**

**Аллааһу ләәә иләәһә илләһүү. Әлхәййүль каййүүм. Ләә тәәхузүһүү синәтү үә ләә нәүүм. Ләһүү мәә фис сәмәәүәәти үә мә филь әрдъ. Мәң зәлләзии йәшфәгүү гиңдәһүү илләә би-изниһ. Йәгьләмү мәә бәйнә әйдииһим үә мәә хальфәһүм. Үә ләә йүхиитуунә бишәй-им мин гильмиһии илләә бимәә шәәә-э. Үәсигә күрсиййүһү-с сәмәәүәәти үәль әрдъ. Үә ләә йәүдүһүү хифзуһүмәә үә һүүә-ль гәлийү-ль гәзыйм».**

*«Гыйбадәт кылырга яраклы һич бер зат юк, мәгәр Аллаһ үзе генә. Ул һәрвакыт тере, бөтен нәрсәгә хуҗа булган хәлдә, һәрвакыт бар. Аны ару, талу һәм йокы тотмас, җирдә һәм күкләрдә булган нәрсәләр аныкы. Ахирәттә Аллаһ хозурында кем кемгә шәфәгать кылыр? Юк, шәфәгать кылучы булмас, һичкем үз теләге белән һичкемгә шәфәгать кыла алмас, мәгәр Аллаһ рөхсәте белән генә шәфәгать кылучы булыр. Аллаһ кешеләрнең үткәндәге барча эшләрен һәм алдагы барча эшләрен белер, кешеләр Аллаһ белеменнән һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ белдергәнне генә белерләр. Аллаһның көрсие күкләрне һәм җирне сыйдырды, Аллаһка җирне һәм күкләрне саклау авыр түгел. Ул Биек һәм Бөектер!». («Бәкара» сүрәсе, 255 нче аять).*



www.darul-kutub.com

## *«Фил» сүрәсе*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
أَلَمْ تَرَ كَيْفَ فَعَلَ رَبُّكَ بِأَصْحَابِ الْفِيلِ ط * أَلَمْ يَجْعَلْ
كَيْدَهُمْ فِى تَضْلِيلٍ لا * وَأَرْسَلَ عَلَيْهِمْ طَيْرًا أَبَابِيلَ لا *
تَرْمِيهِمْ بِحِجَارَةٍ مِنْ سِجِّيلٍ صلا * فَجَعَلَهُمْ كَعَصْفٍ
مَأْكُولٍ.

**«Бисмилләәһи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Әләм тәра кәйфә фәгәлә раббүкә биәсъхәәби-ль фиил. Әләм йәҗгәль кәйдәһүм фии тәдълиил. Үә әрсәлә гәләйһим тайран әбәәбиил. Тәрмииһим бихиҗәәратим миң сиҗҗиил. Фәҗәгәләһүм кәгәсъфим мәәкүүл».**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән.*

*Әй, Мөхәммәд галәйһиссәлам, күрмәдеңме, синең Раббың фил ияләренә нинди җәза биргәнен? Әллә Раббың аларның мәкерләрен батыл кылып, тырышуларын бушка чыгармадымы? Һәм һәлак иту өчен алар өстенә төркем-төркем Әбабиль кошларын җибәрде. Кошлар аларны сиҗҗил ташлары белән атарлар. Шулай итеп аларны тапталган, чәйнәлгән салам кебек итте».*



www.darulkutub.com

## *«Кораеш» сүрәсе*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

لِإِيلَافِ قُرَيْشٍ ۙ * إِيلَافِهِمْ رِحْلَةَ الشِّتَآءِ وَالصَّيْفِ ۚ * فَلْيَعْبُدُوا رَبَّ هَذَا الْبَيْتِ ۙ * الَّذِي أَطْعَمَهُمْ مِنْ جُوعٍ وَآمَنَهُمْ مِنْ خَوْفٍ.

**«Бисмилләәһи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Ли-иилəәфи Курайш. Иилəәфиһим рихлəтəш шитəәә-и үә-с сайф. Фəльйəгьбүдүү раббə һəәзəль бəйт. Əллəзии əтъгəмəһүм миң җүүгыйү үә əәмəнəһүм мин хауф».**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән.*

*Кораеш кабиләсенең өлфәтләнүе була күрсен! Аларның җәй һәм кыш көннәрендә сәүдә белән сәфәрдә йөрүләрендә өлфәтләнүләре була күрсен! Алар иман китереп, шушы Кагъбәнең Раббысы булган Аллаһка гыйбадәт кылсыннар һәм Аның биргән нигъмәтләренә шөкер итсеннәр. Ул – Аллаһ, аларны ачлыктан коткарып тук кылды, һәм аларны һәртөрле куркынычлардан имин кылды».*

www.darul-kutub.com

## *«Магун» сүрәсе*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
أَرَأَيْتَ الَّذِي يُكَذِّبُ بِالدِّينِ ط * فَذَلِكَ الَّذِي يَدُعُّ الْيَتِيمَ
لا * وَلَا يَحُضُّ عَلَى طَعَامِ الْمِسْكِينِ ط * فَوَيْلٌ لِلْمُصَلِّينَ لا
* الَّذِينَ هُمْ عَنْ صَلَاتِهِمْ سَاهُونَ لا * الَّذِينَ هُمْ يُرَاءُونَ لا
* وَيَمْنَعُونَ الْمَاعُونَ.

**«Бисмилләәһи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Әраәйтәл ләзии йүкәззибү бид диин. Фәзәәликәл ләзии йәдүггүль йәтиим. Үә ләә йәхүдду гәләә тагәәмиль мискиин. Фәүәйлүл лиль мүсаллиин. Әлләзиинә һүм гәң саләәтиһим сәәһүүн. Әлләзиинә һүм йүраауун. Үә йәмнәгүүнә-ль мәәгүүн».**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән.*

*Әллә син хисап һәм җәза көнен, кыямәтне ялганга тоткан кешене күрмәдеңме? Ул ялганчы ятимне кагар, аңа золым итәр. Үзен һәм башкаларны фәкыйрьләргә аш һәм сәдака бирергә кызыктырмас. Ни үкенеч һәм һәлакәтлек ихлассыз намаз укучыларга. Алар намазларыннан гафилләр, вакытында укымаслар һәм намазның рөкеннәрен хөрмәт итмәсләр,*

www.darul-kutub.com

*намазларының вакытыннан кичегүенә кайгырмаслар. Әле алар укыган намазларын да рия белән укырлар, ягъни кеше күргәндә укый, кеше күрмәгәндә укымый. Ул (риячылар) тиешле сәдакаларны бирүне тыялар».*

## *«Кәүсәр» сүрәсе*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
إِنَّآ أَعْطَيْنَاكَ الْكَوْثَرَ ۚ * فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ۗ * إِنَّ شَانِئَكَ هُوَ الْأَبْتَرُ.

**«Бисмилләәhи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Иннәәә әгьтайнәәкәль кәүсәр. Фәсалли лираббикә үәнхәр. Иннә шәәни әкә hүүә-ль әбьтәр»**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән.*

*Әй, Мөхәммәд галәйһиссәлам, һичшиксез, Без сиңа күп хәерле нәрсәләр бирдек. Ягъни пәйгамбәрлек дәрәҗәсен, зур белем, күркәм холык һәм ахирәттә кәүсәр елгасын бирдек, ул елга сиңа һәм өммәтеңә хастыр. Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм ятимнәрне, фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал! Шиксез, сине әбетәр дип кимсетүче дошманың үзе әбетәр – нәселе бетүче».*

www.darul-kutub.com

## *«Кәфирун» сүрәсе*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
قُلْ يَاأَيُّهَا الْكَافِرُونَ ۙ * لَآ أَعْبُدُ مَا تَعْبُدُونَ ۙ * وَلَآ أَنْتُمْ عَابِدُونَ مَآ أَعْبُدُ ۚ * وَلَآ أَنَا عَابِدٌ مَا عَبَدتُّمْ ۙ * وَلَا أَنْتُمْ عَابِدُونَ مَآ أَعْبُدُ ۗ * لَكُمْ دِينُكُمْ وَلِيَ دِينِ.

**«Бисмилләәһи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Кул йәәә әййүһәль кәәфируун. Ләәә әгьбүдү мәә тәгьбүдүүн. Үә ләәә әңтүм гәәбидүүнә мәәә әгьбүдү. Үә ләәә әнә гәәбидүм мәә габәттүм. Үә ләәә әңтүм гәәбидүүнә мәәә әгьбүд. Ләкүм диинүкүм үә лийә диин».**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән.*

*Әй, Мөхәммәд галәйһиссәлам, әйт: «Әй, сез, кяферләр, иман китермәгән кешеләр! Сез гыйбадәт кыла торган сыннарга мин гыйбадәт кылмыйм. Һәм сез дә мин гыйбадәт кыла торган Аллаһка гыйбадәт кылмыйсыз. Һәм мин сезнең гыйбадәт кыла торган сыннарыгызга гыйбадәт кылучы түгелмен. Һәм сез дә мин гыйбадәт кыла торган Аллаһка гыйбадәт кылучы түгелсез. Сезнең батыйль ялган динегез үзегезгә булсын, һәм минем хак динем үзебезгә булсын!»*

www.darul-kutub.com

## *«Насыр» сүрәсе*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
إِذَا جَآءَ نَصْرُ اللَّهِ وَالْفَتْحُ ۙ * وَرَأَيْتَ النَّاسَ يَدْخُلُونَ فِي
دِينِ اللَّهِ أَفْوَاجًا ۙ * فَسَبِّحْ بِحَمْدِ رَبِّكَ وَاسْتَغْفِرْهُ ۚ إِنَّهُ
كَانَ تَوَّابًا.

**«Бисмилләәһи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Изәә җәәә-ә нәсърулллаһи үә-ль фәтх. Үә раәйтә-н нәәсә йәдхулүүнә фии диинилләәһи әфүәәҗәә. Фәсәббих бихәмди раббикә үәстәгъфирьһ. Иннәһүү кәәнә тәүүәәбәә».**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән.*

*Әгәр Ислам диненә һәм мөселманнарга Аллаһтан ярдәм килсә, һәм шәһәрләр хосусән Мәккә шәһәре кебек мөселманнар кулына үтсә, шул вакытта күрерсез кешеләрне, төркем-төркем булып Аллаһ дине Исламга керерләр. Раббың булган Аллаһны һәр кимчелектән пакь дип белеп һәм мактап тәсбих әйт, намаз укы һәм Аңардан ярлыкауны телә, сора! Дөреслектә, Ул тәүбәне кабул итеп, гөнаһларны гафу кылучы».*

## *«Мәсәд» сүрәсе*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

تَبَّتْ يَدَا أَبِي لَهَبٍ وَتَبَّ ط * مَا أَغْنَى عَنْهُ مَالُهُ وَمَا كَسَبَ

ط * سَيَصْلَى نَارًا ذَاتَ لَهَبٍ ج * وَامْرَأَتُهُ ط حَمَّالَةَ الْحَطَبِ

ج * فِي جِيدِهَا حَبْلٌ مِنْ مَسَد.

**«Бисмилләәһи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Тәббәт йәдәәә әбии ләһәбиү үә тәббь. Мәәә әгънәә гәнһүү мәәлүһүү үә мәә кәсәбь. Сәйәсъләә нәәраң зәәтә ләһәбь. Үәмраәтүһүү. Хәммәәләтә-ль хәтабь. Фии җиидиһәә хәблүм мим мәсәдь».**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән.*

*Әбү Ләһәбнең ике кулы корыды һәм һәлак булды! Аңа газабтан котылырга малы да, кәсеп иткән нәрсәләре дә һич файда бирмәде. Тиздән ул Әбү Ләһәб ялкынлы утка кереп янар. Дәхи хатыны да утка керер утын күтәргән хәлдә. Ул хатынның муенында хөрмә мунчаласыннан булган бау бар».*

www.darul-kutub.com

## *«Ихлас» сүрәсе*

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ ۚ * اللَّهُ الصَّمَدُ ۚ * لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ ۙ
* وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ.

**«Бисмилләәһи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Куль һүүәллааһу әхәд. Аллааһу-с самәд. Ләм йәлид үә ләм йүүләд. Үә ләм йәкүл ләһүү күфүүән әхәд».**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән.*

*Әйт, (әй, Мөхәммәд): «Ул – Аллаһ, һич тиңдәше һәм охшашы булмаган бер генә Аллаһтыр. Һичнәрсәгә, һичбер мәхлукка ихтыяҗы юк, бәлки һәр мәхлукның хаҗәтен үтәүче Аллаһтыр. Ул һичкемне тудырмады һәм һичкемнән тудырылмады. Һәм һичкем Аңа тиң булмады».*

www.darul-kutub.com

## *«Фәләкъ» сүрәсе*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ ۙ * مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ ۙ * وَمِنْ شَرِّ
غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ ۙ * وَمِنْ شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي الْعُقَدِ ۙ * وَمِنْ
شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ.

**«Бисмилләәһи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Куль әгүүзү бираббиль фәләкъ. Миң шәрри мәә халәкъ. Үә миң шәрри гаасикыйн изәә үәкабь. Үә миң шәрри-н нәффәәсәәти фи-ль гүкадь. Үә миң шәрри хәәсидин изә хәсәд».**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән.*

*Әйт, Мөхәммәд: «Мин таңның Раббысы Аллаһ Тәгаләгә куренеп һәм куренмичә кылә торган һәр төрле зарарлардан сыенам. Бар кылынган, яратылган һәр мәхлукның нинди булса да зарарыннан һәм һәрвакыт караңгылыгы белән җир өстен каплаган караңгы төннең зарарыннан сыгынам. Хәтта сихер-ырым төеннәренә төкеруче, өруче, сихерче хатыннар явызлыгыннан, зарарыннан сыгынам. Һәм һәрвакыт ул көнчелек ачуы белән зарар тидерергә теләгән көнче дошманның явызлыкларыннан, зарарларыннан сыенам».*



www.darul-kutub.com

## *«Нәс» сүрәсе*

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ النَّاسِ ۙ * مَلِكِ النَّاسِ ۙ * إِلَهِ النَّاسِ ۙ *
مِنْ شَرِّ الْوَسْوَاسِ الْخَنَّاسِ ۙ * الَّذِي يُوَسْوِسُ فِي صُدُورِ
النَّاسِ ۙ * مِنْ الْجِنَّةِ وَالنَّاسِ.

**«Бисмилләәhи-р рахмәәни-р рахиим.**

**«Куль әгүүзү бирабби-н нәәс. Мәлики-н нәәс. Иләәhи-н нәәс. Миң шәрри-ль үәсүәәси-ль ханнәәс. Әлләзии йүүәсүисү фии судүүри-н нәәс. Минә-ль җиннәти үә-н нәәс».**

*«Мәрхәмәтле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән.*

*Әйт: «Кешеләрнең Раббысы булган Аллаһка сыгынам. Кешеләрнең патшасы булган Аллаһка сыгынам. Кешеләрнең гыйбадәт кыла торган Илаһысы булган Аллаһка сыгынам. Чигенә-чигенә саваплы эштән тыеп, гөнаһлы эшкә өндәп вәсвәсә кылучы ханнәснең зарарыннан. Ул ханнәс кешеләрнең күңеленә явызлыкны сала. Ул ханнәс җеннәрдән дә һәм кешеләрдән дә бар».*

www.darul-kutub.com

# Намаз эчендә укыла торган кайбер догалар

سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ وَ بِحَمْدِكَ و تبَارَكَ اسْمُكَ
وَ تعَالَى جَدُّكَ (وَ جَلَّ ثنَاؤُكَ ) وَ لاَ إِلَهَ غَيْرُكَ.

**«Сүбхәәнәкәллааһүммә үә бихәмдикә үә тәбәәракә смүкә үә тәгәәләә җәддүкә (үә җәллә сәнәәәүкә) үә ләәә иләәһә гайрук».**

*«Аллаһым! Синең пакьлегеңне һәм мактаулыгыңны беләм. Синең исемең мөбарәк һәм дәрәҗәң олугъ. Синнән башка һичбер илаһ юк».*

## *«Әт-Тәхиййәт»*

التَّحِيّاتُ للهِ وَالصَّلَوَاتُ والطَّيِّباتُ ، السَّلامُ عَلَيكَ أَيُّها
النَّبِىُّ وَرَحْمَةُ اللهِ وَبرَكاتُهُ. السَّلامُ عَلَيْنَا وَعَلَى عِبادِ للهِ
الصَّالِحِين . أَشْهَدُ أَنْ لَا إِلهَ إِلاَّ اللهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّداً
عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ

**«Әт-тәхиййәәтү лилләәһи үә-с саләүәәтү үә-т**

www.darul-kutub.com

**таййибәәт. Әс-сәләәму гәләйкә әййүһә-н нәбиййү үә рахмәтүллааһи үә бәракәәтүһ. Әс-сәләәму гәләйнәә үә гәләә гибәәдилләәһи-с саалихиин. Әшһәду әл ләәә иләәһә илләллааһ үә әшһәду әннә Мүхәммәдән гәбдүһүү үә расүүлүһ».**

*«Тел гыйбадәтләре дә, тән гыйбадәтләре дә, мал гыйбадәтләре дә һәркайсы Аллаһ Тәгалә өчен. Әй, Пәйгамбәребез, сиңа Аллаһ Тәгаләнең сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәтләре булсын. Шулай ук сәлам безгә һәм Аллаһ Тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә дә булсын. Шаһитлек бирәм, һичшиксез, Аллаһ Тәгаләдән башка һичбер илаһ юк һәм Мөхәммәд галәйһиссәлам Аллаһ Тәгаләнең колы һәм илчесе».*

## *«Салават»*

اللّٰهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ. كَمَا صَلَّيْتَ
عَلى إِبْراهِيمَ وَعَلى آلِ إِبْراهِيم. إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ

**«Аллааһүммә салли гәләә Мүхәммәдиү үә гәләәә әәли Мүхаммәд. Кәмәә салләйтә гәләәә Ибрааһимә үә гәләәә әәли Ибрааһим. Иннәкә хәмиидүм мәҗиид».**

*«Йә, Аллаһым! Ибраһим галәйһиссәламгә һәм аның әһеленә салават ирештергәнең кебек, Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәм аның әһеленә дә салават ирештер! Шиксез, Син мактаулы һәм олугсың».*

اللّٰهُمَّ بَارِكْ عَلى مُحمَّدٍ وَعَلى آلِ مُحمَّدٍ. كَمَا بَارِكْتَ عَلى إِبْراهِيمَ وَعَلى آلِ إِبْراهِيمَ. إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ

**«Аллаһүммә бәәрик галәә Мүхәммәдиү үә гәләәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәракьтә гәләәә Ибрааһиимә үә гәләәә әәли Ибрааһиим. Иннәкә хәмиидүм мәҗиид»**

*«Йә, Аллаһым! Ибраһим галәйһиссәламгә һәм аның әһеленә бәрәкәт ирештергәнең кебек, Мөхәммәд галәйһиссәламгә һәм аның әһеленә дә бәрәкәт бир! Шиксез, Син мактаулы һәм олугсың».*

## *«Раббәнә әтинә»*

رَبَّنَا اَتِنَا فِى الدُّنْيَا حَسَنَةً وَ فِى الْاَخِرَةِ حَسَنَةً وَ قِنَا عَذَابَ النَّارِ * رَبَّنَا اغْفِرْ لِى وَ لِوَالِدَىَّ وَ لِلْمُؤْمِنِينَ يَوْمَ يَقُومُ الْحِسَابُ.



www.darul-kutub.com

**«Раббәнәәә әәтинәә фи-д дуньйәә хәсәнәтәү үә фи-ль әәхыйрати хәсәнәтәү үә кыйнәә гәзәәбә-н нәәр».**

*«Әй, Раббыбыз! Безгә дөньяда матур тормыш бир һәм ахирәттә дә матур тормыш бир һәм Җәһәннәм утыннан безне сакла».*

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм «Раббәнә»дән соң тагын догалар укый торган булган. Хәзрәти Гаишә (Аллаһ аннан риза булсын!) бу хакта әйтеп калдырган: «Расулүллаһ салләллаһу галәйһи үәсәлләм намазда утырганда бу доганы укыган:

اللَّهُمَّ إِنِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابِ الْقَبرِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْمَسِيحِ الدُّجَّالِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ المحْيَا و مِنْ فِتْنَةِ الْمَمَاتِ. اللَّهُمَّ إِنِّ أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْمَاْثَمِ وَ الْمَغْرَمِ.

**«Аллааһүммә иннииии әгүүзү бикә мин гәзәәби-ль кабьри үә әгүүзү бикә миң фитнәти-ль мәсиихи-д дәҗҗәәли үә әгүүзү бикә миң фитнәти-ль мәхьйәә үә миң фитнәти-ль мәмәәт. Аллааһүммә иннииии әгүүзү бикә минә-ль мәәсәми үә-ль мәгърам».**

*«Йә, Аллаһым! Мин Сиңа сыенамын кабер газабыннан, Дәҗҗал явызлыгыннан, тормыш һәм үлем коткысыннан. Йә, Аллаһым, дөреслектә, мин Сиңа сыенамын гөнаһтан һәм зарардан!» (Бохари, «Азан»: 149).*

## *Кунут догалары*

اللَّهُمَّ إِنَّا نَسْتَعِينُكَ وَ نَسْتَغْفِرُكَ وَ نَسْتَهْدِيكَ وَ نُؤْمِنُ بِكَ
وَ نَتُوبُ إِلَيْكَ وَ نَتَوَكَّلُ عَلَيْكَ وَ نُثْنِي عَلَيْكَ الْخَيْرَ كُلَّهُ
نَشْكُرُكَ وَ لاَ نَكْفُرُكَ وَ نَخْلَعُ وَ نَتْرُكُ مَنْ يَفْجُرُكَ.

**«Аллааһүммә иннәә нәстәгиинүкә үә нәстәгъфирукә үә нәстәһдиикә үә нүьминү бикә үә нәтүүбү иләйкә үә нәтәүәккәлү гәләйкә үә нүснии гәләйкәль хайра күлләһүү нәшкүрукә үә ләә нәкфүрукә үә нахъләгү үә нәтрукү мәй йәфҗүрукь».**

*«Йә, Аллаһым! Һичшиксез, без Синнән ярдәм көтәбез һәм Синнән гөнаһларыбызны ярлыкавыңны сорыйбыз. Һәм Сиңа инанабыз һәм тәвәккәл кылып һәрбер эшләребезне Сиңа тапшырабыз. Сине мактыйбыз, Сиңа шөкер кылабыз, көферлек кылмыйбыз. Сиңа гөнаһ кыла торган кешеләрне ташлыйбыз».*

www.darul-kutub.com

اللَّهُمَّ إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَ لَكَ نُصَلِّى وَ نَسْجُدُ وَ إِلَيْكَ نَسْعَى وَ نَحْفِدُ. نَرْجُوا رَحْمَتَكَ وَ نَخْشَى عَذَابَكَ . إِنَّ عَذَابَكَ بِالْكُفَّارِ مُلْحِقٌ.

**«Аллааһүммә иййәәкә нәгьбүдү үә ләкә нүсаллии үә нәсҗүдү үә иләәйкә нәсьгәә үә нахфид. Нәрҗүү рахмәтәкә үә нәхъшәә гәзәәбәкь. Иннә гәзәәбәкә бил күффәәри мүльхикъ».**

*«Йә, Аллаһым! Без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз, Синең өчен генә намаз укыйбыз, сәҗдә кылабыз һәм, гыйбадәт кылып, Сиңа якын булырга тырышабыз. Рәхмәтеңне өмет итәбез, газабыңнан куркабыз. Һичшиксез, Синең газабың имансыз кешеләргә генә ирешүчедер».*

****

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләм намаз укый башлагач, иң беренче итеп «Сүбхәәнәкә» догасын укый торган булган һәм бу хакта аның хатыны Хәзрәти Гаишә сөйләп калдырган (Әбү Дауд: 776).

Мөслим белән Әбү Һүрайра (Аллаһ аннан риза булсын!) Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләмнең тәкбирдән соң кайвакыт «Сүбхәәнәкә» урынына түбәндәге доганы укыганын тапшырганнар:

Әбү Һүрайра әйткән: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм намаз башында тәкбир әйткәннән соң, «Фатиха» сүрәсен укый башлаганчы, бераз тынып торыр иде. Беркөнне мин аннан сорадым: «Йә, Рәсүлүллаһ! Ата-анам сиңа фида булсын! Тәкбир белән кычкырып укый башлаганчы тынып торуыңның сәбәбе нидә? Шуны миңа әйт әле. Ул вакытта син нәрсәләр әйтәсең?» Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи үәсәлләм шушы доганы укыганын әйтте:

اللَّهُمَّ بَادِعْ بَيْنِي وَ بَيْنَ خَطَايَایَ كَمَا بَادَعْتَ بَيْنَ الْمَشْرِقِ وَ الْمَغْرِبِ. اللَّهُمَّ نَقِّنِي مِنْ خَطَايَایَ كَمَا يُنَقَّى الثَّوْبُ الْأَبْيَضُ مِنَ الدَّنَسِ. اللَّهُمَّ اغْسِلْ خَطَايَایَ بِالْمَاءِ وَ الثَّلْجِ وَ الْبَرْدِ.

**«Аллааһүммә бәәгид бәйнии үә бәйнә хатаайәәйә кәмәә бәәгәдтә бәйнә-ль мәшрикый үә-ль мәгъриб. Аллааһүммә нәккыйнии мин хатаайәәйә кәмәә йүнәкка-с сәүбү-л әбьйәду минә-д дәнәс. Аллааһүммә гъсил хатаайәәйә би-ль мәәә-и үә-с сәлҗи үә-ль бәради».**

*«Йә, Аллаһым! Ничек Син көнчыгышны көнбатыштан ерагайткан кебек, мине дә гөнаһларымнан ерак кылсаң иде. Ак киемне пычрактан пакьләгән шикелле, йә, Раббым, мине дә гөнаһларымнан кар, су һәм боз кебек юып чистарт» (Бохари, «Азан»: 79).*

## Намаздан соң укыла торган догалар

الْحَمْدُ للهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ. وَ الصَّلاَةُ وَ السَّلاَمُ عَلَى رَسُولِنَا
مُحَمَّدٍ وَ عَلَى اَلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ. اللَّهُمَّ إِنَّا نَعُوذُ بِكَ
مِنْ جَهْدِ الْبَلاَءِ و دَرْكِ الشَّقَاءِ وَ سُوءِ الْقَضَاءِ وَ شَمَاتَةِ
الْأَعْدَاءِ . اللَّهُمَّ اغْفِرْ لَنَا وَ ارْضَ عَنَّا وَ تَقَبَّلْ مِنَّا
وَ أَدْخِلْنَا الْجَنَّةَ وَ نَجِّنَا مِنَ النَّارِ. وَ أَصْلِحْ لَنَا شَأْنَنَا كُلَّهُ.
اللَّهُمَّ أَعِنَا عَلَى ذِكْرِكَ وَ شُكْرِكَ وَ حُسْنِ عِبادَتِكَ. اللَّهُمَّ
أَحْسِنْ عَاقِبَتَنَا فِى الْأُمُورِ كُلِّهَا أَجِرْنَا مِنْ خِزْىِ الدُّنْيَا و

www.darulkutub.com

عَذَابِ الْاَخِرَةِ. اللَّهُمَّ إِنَّا نَسْأَلُكَ موجِبَاتِ رَحْمَتِكَ وَ
عَزَائِمَ مَغْفِرَتِكَ وَ السَّلاَمَةَ مِنْ كُلِّ إِثْمٍ وَ الْغَنِيمَةَ مِنْ كُلِّ
بِرٍّ وَ الْفَوْزِ بِالْجَنَّةِ وَ النَّجَّاةَ من النَّارِ. اللَّهُمَّ لاَ تَدَعْ لَنَا
ذَنْبًا إِلاَّ غَفَرْتَهُ , وَ لاَ هَمًّا إِلاَّ فَرَجْتَهُ وَ لاَ دَيْمًا إِلاَّ قَضَيْتَهُ
وَ لاَ حَاجَةَ مِنْ حَوَائِجِ الدُّنْيَا وَ الاَخِرَةِ هِىَ لَكَ رِضًا
إِلاَّ قَضَيْتَهَا يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ. اللَّهُمَّ رَبَّنَا اَتِنَا فِى الدُّنْيَا
حَسَنَةً وَ فِى الْاَخِرَةِ حَسَنَةً وَ قِنَا عَذَابَ النَّارِبِرَحْمَتِكَ يَا
أَرْحَامُ الرَّاحِمِينَ. رَبَّنَا اغْفِرْلِى وَ لِوَالِدَىَّ وَ لِلْمُؤْمِنِينَ يَوْمَ
يَقُومُ الْحِسَابُ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَامُ الرَّاحِمِينَ. وَ سَلاَمٌ عَلَى
الْمُرْسَلِينَ وَ الْحَمْدُ للهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ.

**«Әлхәмдү лилләәһи рабби-ль гәәләмиин. Үә-с саләәтү үә-с сәләәмү гәләә расүүлинәә Мүхәммәдиү үә гәләәә әәлиһи үә сахбиһии әҗмәгиин. Аллааһүммә иннәә нәгүүзү бикә миң җәһди-ль бәләәәи үә дәрки-ш шәкааа-и үә сүүүи-ль кадааа-и үә шәмәәтәти-ль агъдәәә-э. Аллааһүммә гъфир ләнәә үәрда гәннәә үә тәкаббәл миннәә үә әдхыйльнә-ль җәннәтә үә нәҗҗинәә минә-н нәәр. Үә әсълих ләнәә шәәнәнәә күлләһ. Әллааһүммә әгиннәә гәләә зикрикә үә шүкрикә**

**үә хүсни гибәәдәтик. Әллааһүммә әхсин гәәкыйбәтәнәә фи-ль үмүүри күллиһәә үә әҗирнәә мин хыйзьйи-д дүньйәә үә гәзәәби-ль әәхыйраһ. Әллааһүммә иннәә нәсь-әлүкә мүүҗибәәти рахмәтикә үә гәзәәәимә мәгъфиратикә үә-с сәләәмәтә миң күлли исмиү үә-ль ганиимәтә миң күлли бирриү үә-ль фәүзә би-ль җәннәти үә-н нәҗәәтә минә-н нәәр. Әллаһүммә ләә тәдәгь ләнәә зәмбән илләә гафәртәһү үә ләә һәммән илләә фәрраҗтәһү үә ләә дәйнән илләә кадайтәһү үә ләә хәәҗәтәм мин хәүәәәиҗи-д дүньйәә үә-ль әәхыйрати һийә ләкә ридан илләә кадайтәһәә йәә әрхәмә-р раахимиин. Әллааһүммә раббәнәәә әәтинәә фи-д дүньйәә хәсәнәтәү үә фи-ль әәхыйрати хәсәнәтәү үә кыйнәә гәзәәбә-н нәәр, бирахмәтикә йәәә әрхәмә-р раахимииң. Үә сәләәмүн гәлә-ль мүрсәлиинә үә-ль хәмдү лилләәһи рабби-ль гәәләмиин».**

*«Чын мактау галәмнәрне, барлык мәхлукларны тәрбияләүче Аллаһ Тәгаләгә тиешле. Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә, аның гаилә әһелләренә һәм сәхабаларына сәлам һәм салават булсын! Йә, Аллаһым! Бәланең һөҗүменнән, азгынлыкка төшүдән, төрле афәт-бәхетсезлекләрдән, дошманнардан Сиңа гына сыенабыз. Йә, Аллаһым, безне гафу кыл, бездән риза бул, безнең иге-*

*лекле гамәлләребезне кабул кыл, безгә Җәннәтне насыйп әйлә һәм Җәһәннәмнән сакла, гамәлләребезне дөреслә. Йә, Аллаһым! Сине зикер итәргә, Сиңа шөкер итәргә, Синең игелекле колларың булырга ярдәм ит! Йә, Аллаһым! Безнең ахырыбызны һәр очракта да яхшы ит, дөньялыкта ташландык хәлдә калдырма, ахирәт газабыннан сакла! Йә, Аллаһым! Без Синең рәхмәт-мәрхәмәтеңә мохтаҗ, гафу кылуыңны өметләнәбез, һәр гөнаһтан саклавыңны, һәртөрле яхшылыкка ирешүебезне, Җәннәткә ирешеп, Җәһәннәмнән котылуыбызны Синнән телибез/көтәбез. Йә, Аллаһым! Безнең өстебездә гафу кылынмаган бер гөнаһ, сөенечкә әйләндермәгән бер борчу-газап, түләнмәгән бер бурыч калдырма. Дөньялыкта булсын яки ахыйрәттә булсын, Син ризалыгың белән безнең ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерәсең. Син мәрхәмәтлеләрнең мәрхәмәтлесе!*

*Йә, Аллаһым! Раббыбыз! Безгә дөньялыкта да, ахыйрәттә дә игелекләр насыйп ит. Әй, мәрхәмәтлеләрнең мәрхәмәтлесе, рәхмәтең белән безне ут газабыннан сакла! Рәхмәтең белән догаларыбызны кабул ит. Пәйгамбәрләргә сәлам булсын, галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһ Тәгаләгә хәмед булсын!»*

# Намаздан соң укыла торган тагын бер дога

اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ مِنَ الْخَيْرِ كُلِّهِ عَاجِلِهِ وَ اٰجِلِهِ مَا عَلِمْتُ
مِنْهُ وَ مَا لَمْ أَعلَمْ. وَ أَعُوذُ بِكَ مِنَ الشَّرِّ كُلِّهِ عَاجِلِهِ وَ
اٰجِلِهِ مَا عَلِمْتُ مِنْهُ وَ مَا لَمْ أَعْلَمْ. وَ أَسْأَلُ مِنْ خَيْرِ مَا
سَأَلكَ عَبدُكَ وَ رَسولُكَ مُحَمَّدٌ صَلَّى اللّٰهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ. وَ
أَسْتَعِيذُكَ مِنْ مُسْتَعَاذِ عَبْدِكَ وَ رَسولِكَ مُحَمَّدٌ صَلَّى اللّٰهُ
عَلَيْهِ وَسَلَّمَ. وَ أَسْأَلُكَ مَا قَضَيْتَ لِى مِنْ أَمْرٍ تَجْعَلَ عَاقِبَتَهُ
رُشْدًا بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ.

**«Аллааһүммә инниии әсь-әлүкә минә-ль хайри күллиһии гәәҗилиһии үә әәҗилиһии мәә гәлимтү миңһү үә мәә ләм әгьләм. Үә әгүүзү бикә миңә-ш шәрри куллиһии гәәҗилиһии үә әәҗилиһии мәә гәлимтү миңһү үә мәә ләм әгьләәм. Үә әсь-әлүкә мин хайри мәә сә-әләкә гәбдүкә үә расүүлүкә Мүхәммәдүң салләллаһу гәләйһи үәсәлләм. Үә әстәгиизүкә мим мүстәгәәзи гәбдикә үә расүүликә Мүхәммәдиң салләллаһу гәләйһи үәсәлләм. Үә әсь-әлүкә мәә кадайтә лии мин әмриң тәҗгәлә гәәкыйбәтәһү рушдәм бирахмәтикә йәәә әрхәмә-р раахимиин».**

www.darul-kutub.com

*«Йә, Аллаһым! Белгән һәм белмәгән, хәзерге һәм киләчәктә буласы һәр төрле зарардан Сиңа сыенам. Синнән Җәннәт өмет итәм һәм Җәннәткә якынайтучы сүз һәм гамәлләрне насыйп итүеңне үтенәм.*

*Колың һәм расүлең булган Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләмнең, Синнән теләгән хәерен сорыйм. Колың һәм расүлең булган Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләмнең Сиңа сыгынган нәрсәләреннән Сиңа сыгынам. Минем өлешемә тиешле һәр нәрсәнең ахырын хәерле итеп язуыңны үтенәм. Әй, мәрхәмәтлеләрнең мәрхәмәтлесе, теләгәннәремне тормышка ашыр!»*

## Намаздан соң укыла торган тагын бер дога

اللَّهُمَّ إِنِّ أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْهَمِّ وَ الْحُزْنِ وَ الْعَجْلِ وَ الْكَسَلِ وَ الْبُخْلِ وَ الْجُبْنِ وَ الْهَرَمِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ أَنْ أُرَدَّ إِلَى أَرْزَلِ الْعُمُرِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْمَحْيَا وَ الْمَمَاتِ , وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابِ الْقَبْرِ.

www.darul-kutub.com

**«Аллааһүммә инниии әгүүзү бикә минә-ль һәмми үә-ль хүзни үә-ль гәҗзи үә-ль кәсәли үә-ль бүхъли үә-ль җүбни үә-ль һәрами үә әгүүзү бикә мин ән үраддә иләәә әрзәли-ль гумүри үә әгүүзү бикә миң фитнәти-ль мәхьйәә үә-ль мәмәәти үә әгүүзү бикә мин гәзәәби-ль кабьри»**

*«Йә, Аллаһым, мин Сиңа сыенам хакыйкатьтә, тынычсызлык һәм хәсрәттән, көчсезлек һәм ялкаулыктан, саранлык һәм кыюсызлыктан, харамнан, хәлсезләнгән картлыктан, томыш һәм үлем коткысыннан һәм кабер газабыннан» (Бохари, «Җиһад»: 25).*

## Күз тиюдән саклану өчен укыла торган дога

Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм күз тимәсен өчен Хәсән белән Хөсәенгә бу доганы укый торган булган:

أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللهِ التَّامَّةِ مِنْ كُلِّ شَيْطَانٍ وَ هَامَّةٍ وَ مِنْ كُلِّ عَيْنٍ لاَمَّةٍ.

**«Әгүүзү бикәлимәәтил ләәһи-т тәәәммәти миң күлли шәйтааниү үә һәәәммәтиү үә миң күлли гәйнил ләәәммәһ».**



www.darulkutub.com

*«һәрбер шайтаннан, төрле бөҗәкләрдән һәм һәрбер яман күздән саклар өчен, Аллаһның камил кәлимәләренә сыгынам!» (Бохари: 4/119).*

## Күз тимәсен өчен тагын бер дога

Күз тимәсен өчен «Каләм» сүрәсендәге шушы аятьне Хәсән Басри хәзрәтләре укырга киңәш иткән:

وَإِنْ يَكَادُ الَّذِينَ كَفَرُوا لَيُزْلِقُونَكَ بِأَبْصَارِهِمْ لَمَّا سَمِعُوا الذِّكْرَ وَيَقُولُونَ إِنَّهُ لَمَجْنُونٌ * وَمَا هُوَ إِلَّا ذِكْرٌ لِلْعَالَمِينَ.

**«Үә ий йәкәәдүл ләзиинә кәфәруу ләйүзликуунәкә биәбсаариһим ләммәә сәмигү-з зикра үә йәкуулүүнә иннәһүү ләмәҗнүүн. Үә мәә һүүә илләә зикьрул ли-ль гәәләмиин».**

*«Кяферләр Мөхәммәд, галәйһиссәламнең, Коръән укыганын яки Коръәннән зикер сөйләгәнен ишетсәләр, күзләре белән ашардай булып карарлар һәм ул – Мөхәммәд, галәйһиссәлам, – җүләр, дияләр иде, әмма*

www.darul-kutub.com

*ул Коръән мәҗнүнлек сәбәбе белән булган нәрсә түгел, бәлки адәмнәр һәм җеннәр өчен булган Аллаһыны зикер иту» («Каләм» сүрәсе, 51-52 нче аятьләр).*

## Рәҗәп ае башлангач укыла торган дога

اللَّهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِي رَجَبٍ وَ شَعْبَانِ وَ بَلِّغْنَا رَمَضَانَ.

**«Әллааһүммә бәәрик ләнәә фии раҗәби үә шәгъбәәнә үә бәллигънәә рамәдаан».**

*«Йә, Аллаһым! Рәҗәп һәм Шәгъбан айларын безнең өчен мөбарәк кыл һәм безне Рамазан аена ирештер» (Мөслим, «Иман»: 64).*

## Җил искәндә укыла торган дога

Тарихта кайбер өммәтләрнең көчле җил-давыллар белән юк ителүе билгеле. Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм көчле җил купканда шушы доганы укый торган булган:

اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ مِنْ خَيْرِهَا وَ خَيْرِ مَا فِيهَا وَ خَيْرِ مَا أُرْسِلَتْ بِهِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا وَ شَرِّ مَا فِيهَا وَ شَرِّ مَا أُرْسِلَتْ بِهِ.

**«Әллаһүммә иннииии әсь-әлүкә мин хайриһәә үә хайри мәә фииһәә үә хайри мәә үрсиләт биһии үә әгүүзү бикә миң шәрриһәә үә шәрри мәә фииһәә үә шәрри мәә үрсиләт биһ».**

*«Йә, Аллаһым! Дөреслектә, мин Синнән сорыйм: бу җилне хәерле кыл, үзе белән алып килгәнен дә хәерле кыл һәм аның белән җибәрелгәнне дә хәерле кыл. Бу җилнең яманлыгыннан, аның белән җибәрелгәннең дә яманлыгыннан Сиңа ялварам!» (Мөслим, «Истиска»: 3).*

## Иртәнге намазлардан соң укыла торган дога

Габдуллаһ ибне Мәсуд (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләм әйткән: «Бу доганы укыган кешегә Исмәгыйль угылларының дүрт колны азат иткән сабавы бирелер:

لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ, لَهُ الْمُلْكُ وَ لَهُ الْحَمْدُ
وَ هُوَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ

**«Ләәә иләәһә илләллаһу үәхдәһү ләә шәриикә ләһүү, ләһү-л мүлку үә ләһү-л хәмду үә һүүә гәләә күлли шәй-иң кадиир».**

*«Аллаһтан башка һичбер илаһ юк. Ул үзе генә. Ул һәрнәрсәгә хуҗа. Аңа мактау булсын! Аның һәрнәрсәгә көч-куәте җитә!» («Фәтху-л бари»: 13/460).*

Кайбер риваятьләрдә әйтелгәнчә, «ун тапкыр укылса, кылган гөнаһларның кәффәрәте булыр». Ә берничәсендә «Бу дога диңгез күбеге санынча укылганда, гөнаһларга кәффәрат булыр» диелгән.

## Салават-и Мөнҗия

اللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ وَ عَلَى اَلِ سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ
صَلاَةً تُنْجِينَا بِهَا مِنْ جَمِيعِ الْأَهْوَالِ وَ الْآفَاتِ وَ تَقْضِى
لَنَا بِهَا جَمِيعَ الْحَاجَاتِ وَ تُطَهِرْنَا بِهَا مِنْ جَمِيعِ السَّيِّئَاتِ
وَ تَرْفَعُنَا بِهَا أَعْلَى الدَّرَجَاتِ وَ تُبَلِّغُنَا بِهَا أَقْصَى



www.darul-kutub.com

الْغَايَاتِ مِنْ جَمِيعِ الْخَيْرَاتِ فِى الْحَيَاةِ وَ بَعْدَ الْمَمَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

**«Әллааһүммә салли гәләә сәййидинәә Мүхәммәдиү үә гәләәә әәли сәййидинәә Мүхәммәд, саләәтәң түңҗиинәә биһәә миң җәмииги-ль әһүәәли үә-ль әәфәәт, үә тәкъдый ләнәә биһәә җәмиигә-ль хәәҗәәт, үә түтаһһирунәә биһәә миң җәмииги-с сәййиәәт үә тәрфәгүнәә биһәәә әгълә-д дәраҗәәт үә түбәллигунәә биһәәә әкъса-ль гаайәәти миң җәмииги-ль хайраати фи-ль хәйәәти үә бәгьдә-ль мәмәәт, бирахмәтикә йәәә әрхәмә-р раахимиин».**

*«Йә, Аллаһым! Пәйгамбәребез Мөхәммәд, салләллаһу галәйһи үәсәлләмгә, аның нәсел-нәсәбенә иксез-чиксез салават һәм сәлам булсын. Бу салават-сәламнәр һәм догалар безне һәртөрле бәла-казалардан коткарсын, барча ихтыяҗларыбызны бетереп, безне гөнаһлардан, начарлыклардан пакьләсен. Әй, Раббым! Безне югары дәрәҗәләргә һәм урыннарга күтәр. Бу салаватлар һәм сәламнәр хөрмәтенә яшәвебездә һәм үлемебездә барча изгелекләрнең иң зур тәңгәллегенә ирештер».*

www.darul-kutub.com

# Салават-и Тәфрижия

اللَّهُمَّ صَلِّ صَلاَةً كَامِلَةً وَ سَلِّمْ سَلاَمًا تَامًّا عَلَى سَيِّدِنَا
مُحَمَّدٍ الَّذِى تَنْحَلُّ بِهِ الْعُقَدُ وَ تَنْفَرِجُ بِهِ الْكُرَبُ وَ
تُقْضَى بِهِ الْحَوَائِجُ وَ تُنَالُ بِهِ الرَّغَائِبُ وَ حُسْنُ الْخَوَاتِمِ وَ
يَسْتَسْقَى الْغَمَامَ بِوَجْهِهِ الْكَرِيمِ وَ علَى اَلِهِ وَ صَحْبِهِ فِى
كُلِّ لَمْحَةٍ وَ نَفَسٍ بِعَدَدِ كُلِّ مَعْلُومٍ لَكَ.

**«Әллааһүммә салли саләәтәң кәәмиләтәү үә сәллим сәләәмәң тәәәммән гәләә сәййидинәә Мүхәммәдинил ләзии тәнхәллү биһи-ль гүкад, үә тәңфәриҗү биһи-ль күраб, үә түкъдаа биһи-ль хәүәәәиҗү үә түнәәлү биһи-р рагаааибү үә хуснү-ль хәүәәтими үә йүстәскал гамәәму биүәҗһиһи-ль кәриим, үә гәләәә әәлиһии үә сахбиһи фии күлли ләмхәтиү үә нәфәсим бигәдәди күлли мәгълүүмил ләк».**

*«Әй, Раббым! Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи үәсәлләмгә аның якыннарына һәм сәхәбәләренә һәрвакыт, даими, санын үзең генә белә торган саннар кадәр, иң өстен һәм камил бер рәвештә салават-сәлам булсын. Ул шундый пәйгамбәр*

www.darul-kutub.com

*ки, чишелмәгән төеннәр аның хәтерендә чишелер, кайгы-хәсрәтләр аның сөюе белән югалыр. Яңгырлар аның йөз суы хөрмәтенә яварлар. Сәлам булсын аңа, сәхәбәләренә һәм якыннарына».*

## Салават-и Уммия

اللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ النَّبِيِّ الْأُمِّيِّ وَ عَلَى اٰلِهِ
وَ صَحْبِهِ وَ سَلِّمْ.

**«Әллааһүммә салли гәләә сәййидинәә Мүхәммәдини-н нәбиййи-ль үммиййи үә гәләәә әәлиһии үә сахбиһии үә сәллим».**

*«Йә, Аллаһым! Өммәтнең пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләмгә, аның гаилә әһелләренә һәм сәхәбәләренә саләт һәм сәламнәр булсын!»*

## Салават-и Фәтхия

اللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ الْفَاتِحِ لِمَا أُغْلِقَ
وَ الْخَاتِمِ لِمَا سَبَقَ نَاصِرِ الْحَقِّ وَ الْهَادِي إِلَى صِرَاطِكَ
الْمُسْتَقِيمِ وَ عَلَى اٰلِهِ حَقَّ قَدْرِهِ وَ مِقْدَارِهِ الْعَظِيمِ.



www.darulkutub.com

**«Әллааһүммә салли гәләә сәййидинәә Мүхәммәдини-ль фәәтихи лимәә үгълика үә-ль хаатими лимәә сәбәка нәәсыйри-ль хәккый би-ль хәккый үә-ль һәәдии иләә сыйраатыйкә-ль мүстәкыйм. Үә гәләәә әәлиһии хәкка кадьриһии үә микъдәәриһи-ль гәзыйм».**

*«Йә, Аллаһым! Бикләнгән капкаларны ачучы, пәйгамбәрләрнең ахыргысы, хакка хак белән ярдәм итүче, Синең тугры юлыңа күндерүче пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләмгә, аның гаиләсенә һәм сәхәбәләренә аларның дәрәҗәләре, абруйлары һәм бөеклекләре кадәр рәхмәт әйлә!»*

## Сәййидү-ль Истигъфар

Габдуллаһ ибне Бүрәйдә (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырган: Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм әйткән: «Сәййидү-ль Истигъфар»ны укыган кеше шул көнне үлсә, Җәннәткә керер. Кичен шушы доганы нык ышану белән укыган кеше шул ук кичтә үлеп китсә, Җәннәткә керер»:

www.darul-kutub.com

اللَّهُمَّ أَنْتَ رَبِى لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ خَلَقْتَنِى وَ أَنَا عَبْدُكَ وَ وَ أَنْتَ عَلَى عَهْدِكَ وَ وَعْدِكَ مَا اسْتَطَعْتُ. أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا صَنَعْتُ أَبُوءُ إِلَيْكَ بِنِعْمَتِكَ عَلَّى وَ اعْتَرِفُ بِذُنوبِى فَاغْرِفْ لِى ذُنُوبِى إِنَّهُ لاَ يَغْفِرُ الذُنُوبَ إِلاَّ أَنْتَ.

**«Әллааһүммә әңтә раббии, ләәә иләәһә илләәә әңтә, халәкътәнии үә әнә гәбдүкә үә әнә гәлә гәһдикә үә үәгьдикә мә стәтагьтү. Әгүүзү бикә миң шәрри мәә санәгътү, әбүүү-ү иләйкә бинигьмәтикә гәләййә үә әгьтәрифү бизүнүүбии фәгъфир лии зүнүүбии. Иннәһүү ләә йәгъфиру-з зүнүүбә илләәә әңт».**

*«Йә, Аллаһым! Син минем Раббым. Синнән башка илаһ юк. Мине Син яраттың. Мин Синең колың. Сиңа биргән вәгъдәмне көчем җиткән кадәр үтәргә тырышырмын. Кылган яманлыкларымнан Сиңа сыенам. Миңа биргән нигъмәтләреңне таныйм һәм гөнаһларымны да таныйм. Гафу ит мине. Чөнки гөнаһларны Син генә ярлыкый аласың» (Әбү Дауд: 5070).*

www.darulkutub.com

# Йокларга яткач укыла торган дога

Хәзрәти Гали (Аллаһ аннан риза булсын!) Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләмнең әлеге доганы йокларга ятканда укыганын сөйләп калдырган:

اللَّهُمَّ أَسْلَمْتُ نَفْسِى إِلَيْكَ وَ وَجَّهْتُ وَجْهِى إِلَيْكَ وَ فَوَّضْتُ أَمْرِى إِلَيْكَ وَ أَلْجَأْتُ ظَهْرِى إِلَيْكَ , اَمَنْتُ بِكِتَابِكَ الْمُنْزَلِ وَ نَبِيِّكَ الْمُرْسَلِ.

**«Әллааһүммә әсләмтү нәфсиии иләәйкә үә үәҗҗәһтү үәҗһиии иләйкә үә фәүүәдътү әмриии иләйкә үә әлҗәәтү заһрииии иләйкә әәмәңтү бикитәәбикә-ль мүңзәли үә нәбиййикә-ль мүрсәл».**

*«Йә, Аллаһым! Мин Сиңа тәвәккәл кылдым, үземнең эшемне Сиңа тапшырдым, йөземне Сиңа юнәлдердем, үземнең теләгем һәм куркуым белән Сиңа тапшырылдым. Мин иңдерелгән Синең китабыңа, безгә җибәрелгән хак пәйгамбәргә ышандым» (Нәсаи: 772).*

Бәра ибн Газиб (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырганча, Аллаһ Расүле

www.darul-kutub.com

салләллаһу галәйһи үәсәлләм йоклар алдыннан бу доганы укыган:

بِسْمِكَ أَحْيَى وَ أَمُوتُ.

**«Бисмикә әхьйәә үә әмүүт».**

*«Синең исемең белән мин уләм һәм Синең исемең белән терелермен».*

Бу хактагы хәдисне төрлечә тапшырганнар. Хәзрәти Хөзайфә (Аллаһ аннан риза булсын!) бу доганы тапшырган:

اللَّهُمَّ بِسْمِكَ أَحْيَى وَأَمُوتُ.

**«Әллааһүммә бисмикә әхьйәә үә әмүүт».**

*«Йә, Аллаһым! Синең исемең белән мин уләм һәм Синең исемең белән терелермен» (Нәсаи, «Амәлу-л йәүм»: 749).*

Ә кайбер риваятьләрдә исә «үлем» сүзе «хәят» (тормыш) сүзеннән алда китерелгән.

www.darul-kutub.com

# Йокыдан уянгач укыла торган дога

Бәра ибн Газиб (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырганча, Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм, йокысыннан уянгач, шушы доганы укый торган булган:

الْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِى أَحْيَانَا بَعْدَ مَا أَمَاتَنَا وَ إِلَيْهِ النُّشُورُ.

**«Әлхәмдү лилләәһил ләзии әхьйәәнәә бәгьдә мәәә әмәәтәнәә үә иләйһи-н нүшүүр».**

*«Безне үлгәннән соң терелтүче Аллаһы Тәгаләгә мактаулар булсын! Үлгәннән соң терелеп торгызылу да Аңадыр» (Нәсаи, «Гамәлү-л йәүм»: 772).*

Башка бер риваятьтә әйтелгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләм, иртән уянгач, әлеге доганы укый торган булган:

اللَّهُمَّ بِكَ أَصْبَحْنَا وَ بِكَ أَمْسَيْنَا وَ بِكَ نَحْيَ وَ بِكَ
نَمُوتُ وَ إِلَيْكَ الْمَصِيرُ.



www.darulkutub.com

**«Аллааһүммә бикә әсъбәхнә үә бикә әмсәйнә үә бикә нәхьйәә үә бикә нәмүүтү үә иләәйкә-ль мәсыйр».**

*«Йә, Аллаһым! Синең рәхмәтең белән генә без кичкә хәтле яшәдек, Синең рәхмәтең белән генә без иртәнгә хәтле яшәдек. Син генә безгә яшәешне бирүче, Син генә аңардан безне мәхрүм итүче, хисап көнендә дә Син генә безне терелтәчәксең!» (Тирмизи, «Дәгъват»: 12).*

## Ризык догалары

Гомәр ибне Әбү Саләмә (Аллаһ аннан риза булсын!) сөйләгән: «Мин кечкенәдән Пәйгамбәребез Мөхәммәд, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, химаясендә үстем. Ашарга утыргач, кулларым гел ризык савытлары өстендә уйнап торыр иде. Моңа каршы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләм миңа әйтте:

«Әй, угыл! Ашарга утыргач Аллаһның исемен искә алырга кирәк, уң кул белән һәм үз алдыңнан гына аша», – диде» (Ибне Мажә, 3267).

Хәзрәти Гаишә (Аллаһ аннан риза бул-

сын!) тапшырганча, «Аллаһ Расүле өйдә ашап утырганда, бер бәдәви килеп керде дә аның ризыгын ике кабуда ашап бетерде. Моңа каршы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үәсәлләм әйтте:

«Белегез: әгәр бәдәви «Бисмилләһ» әйткән булса, ризык сезгә дә җиткән булыр иде. Шуңа күрә ашаган саен «Бисмилләһ» әйтергә кирәк. Әгәр берәрегез ашарга утырганда, ягъни ашый башлаганчы әйтергә онытса, исенә төшкәндә «Бисмилләһи фии әүүәлиһии үә әәхыйриһи» (Аллаһның исеме белән ашауның алдында һәм ахырында) дип әйтсен». (Әбү Дауд: 3767).

Әбү Сәгыйд әл-Худри (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырганча, Аллаһ Расүле, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, ашап бетергәч, шушы доганы кыла торган булган:

الْحَمْدُ للهِ الَّذِى اطْعَمَنَا وَ سَقَانَا وَ جَعَلَنَا مُسْلِمِينَ.

**«Әлхәмду лилләәһил ләзи әтъгәмәнәә үә сәкаанәә үә җәгәләнәә мүслимин».**

*«Мине ашаткан һәм эчерткән һәм мине мөселманнардан кылган Аллаһка барлык мактаулар булсын» (Әбү Давуд: 3650).*

Бу ризык догасы күп кенә хәдис җыентыкларында китерелгән.

Моннан тыш Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм ашавын тәмамлаганнан соң укыган башка догалар да бар.

Әбү Үмәмә (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырганча, Мөхәммәд, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, өстәл артыннан торып киткәндә бу доганы укый торган булган:

الْحَمْدُ للهِ حَمْدًا كَثِيرًا طَيِّبًا مُبَارَكًا فِيهِ غَيرُ مُوَدَّعٍ وَ لاَ مُسْتَغْنًى عَنْهُ رَبَّنَا.

**«Әлхәмдү лилләәһи хамдәң кәсираң таййибәм мүбәәракәң фииһи гайра мүүәддәгин үә ләә мүстәгънән гәнһү раббәнәә».**

*«Аллаһка мактау булсын, чиксез, хәерле, рәхмәтле мактаулар булсын. Ул мактауларны ешрак әйтергә тиешбез, туктаусыз мактауларны. Ул мактауларда*

www.darulkutub.com

*без һәрвакыт мохтаҗбыз, безнең Раббыбыз!» (Тирмизи, «Дәгъват»: 56).*

Әнәс бин Мәлик (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырганча, Пәйгамбәребез, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, әйткән: «Ашап бетергәч, әлеге доганы укыган кешенең кылган гөнаһлары ярлыканыр»:

الْحَمْدُ للهِ الَّذِى أَطْعَمَنِى هَذَا وَ رَزَقَنِيهِ مِنْ غَيْرِ حَوْلٍ مِنِّى وَ لاَ قُوَّةٍ.

**«Әлхәмду лилләәһил ләзии әтъгәмәнии һәәзәә үә разәканииһи мин гайри хәүлим миннии үә ләә куүүәһ».**

*«Раббыма мактаулар булсын, Ул мине шушы ризык белән ашатты һәм миңа аны насыйп итте, минем үземдә андый көч-куәт юк!» (Тирмизи, «Дәгъвәт»: 56).*

Хәзрәти Гайсә кыла торган һәм Коръән Кәримдә китерелгән «Маидә» сүрәсенең бер аятендә Аллаһ Тәгалә өйрәткән дога:

اللَّهُمَّ رَبَّنَا أَنْزِلْ عَلَيْنَا مَاءِدَةً مِنَ السَّمَاءِ تَكُونُ لَنَا عِيدًا لِأَوَّلِنَا وَ اَخِرِنَا وَ اَيَةً مِنْكَ ج وَ ارْزُقْنَا وَ أَنْتَ خَيرُ الرَّازِقِينَ



www.darul-kutub.com

**«Әллааһүммә раббәнәәә әңзил гәләйнәә мәәәидәтәм минә-с сәмәәәи тәкүүнү ләнәә гиидәл лиәүүәлинәә үә әәхыйринәә үә әәятәм миңкә үәрзүкънәә үә әңтә хайру-р раазикыйн».**

*«Әй, тәрбиячебез – Аллаһ! Безгә куктән аш өстәле белән ризык иңдер – ризык иңгән көн әувәлгеләребезгә дә һәм ахыргыларыбызга да бәйрәм көне булсын! Янә минем пәйгамбәрлегемә дә дәлил булсын! Йә, Раббыбыз, безне ризыкландыр, Син, әлбәттә, ризыкландыручыларның иң хәерлесе» («Мәидә» сүрәсе, 114 нче аять).*

## Яңа туган баланың колагына әйтелә торган дога

Аллаһ Расүле, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, әйткән: «Берәр кешенең баласы туып, ул баланың уң колагына азан әйтеп, сул колагына камәт әйтелсә, балага беркайчан да авыру тимәс». (Нәвәви, «Әл-Әзкәр»: 253).

www.darul-kutub.com

## Яңа кием кигәндә әйтелә торган дога

Әбү Сәгыйд әл-Худри (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырганча, Пәйгамбәребез, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, яңа кием кигәч, аны гимамә (чалма), күлмәк, рида (ыштан) кебек исемнәр белән атый иде, соңыннан дога кылыр иде:

اللَّهُمَّ لَكَ الْحَمْدُ كَسَوْتَنِي أَسْأَلُكَ خَيْرَهُ وَ خَيرُ مَا صُنِعَ لَهُ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهِ وَ شَرِّ مَا صُنِعَ لَهُ.

**«Әллааһүммә ләкә-ль хәмдү әңтә кәсәүтәнии әсь-әлүкә хайраһүү үә хайра мәә сунигә ләһүү үә әгүүзү бикә миң шәрриһи үә шәрри мәә сунигә ләһ».**

*«Йә, Аллаһым! Сиңа мактаулар булсын! Үзең генә миңа бу киемне кидердең. Киемнең минем өчен яхшы һәм хәерле булуын сорыйм һәм аның яманлыгыннан Сиңа гына сыенам» (Тирмизи, «Либәс»: 29).*

www.darul-kutub.com

# Йолдыз атылганда укыла торган дога

مَا شَاءَ اللّٰهُ لاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللّٰهِ.

**«Мәә шәәә әллаһү ләә куүүәтә илләә билләәһ».**

*«Аллаһ Тәгалә теләгәнчә булыр. Аллаһ куәтеннән башка һичбер көч-куәт юк».*

# Юлга чыгучы кеше кыла торган дога

Әбү Һүрайра (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырганча, бер кеше: «Йә, Расүлүллаһ, мин сәфәргә чыгарга телим. Миңа киңәш бир», – дигән. Пәйгамбәребез аңа әйтте: «Аллаһтан куркырга һәм барган җирләреңдә югарырак урынга чыгып тәкбир әйтергә киңәш итәм».

Әлеге кеше китеп баргач, Мөхәммәд, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, дога кылган:

«Аллаһым! Бу кешенең барган ерак юлын якынайт һәм сәфәрен җиңеләйт» (Тирмизи: 2/244).



www.darul-kutub.com

## Юлда чакта кунарга туктаганда укыла торган дога

Хаулә ибне Хаким (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырганча, Аллаһ Расүле, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, әйткән: «Сәфәрдәге кеше берәр урында төнгә кунарга туктаганда шушы доганы кылса, бу урыннан кузгалып киткәнчегә кадәр аңа бернинди дә зарар килмәс»:

أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللهِ التَّامَّةِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ.

**«Әгүүзү бикәлимәәтил ләәһи-т тәәәммәти миң шәрри мәә халәкъ».**

*«Аллаһ Тәгалә барлыкка китергәннең явызлыгыннан Үзенә генә сыенам!» (Тирмизи, «Дәгъват»: 46).*

## Юлдан кайткач кылына торган дога

Әнәс ибне Мәлик (Аллаһ аннан риза булсын!) сөйләп калдырган: «Усфаннан кайтып килгәндә без Пәйгамбәребез

www.darul-kutub.com

салләллаһу галәйһи үәсәлләм белән икәү бергә идек. Мәдинә күренә башлагач, ул бер дога укый башлады һәм аны Мәдинәгә килеп кергәнчегә кадәр кабатлап кайтты. Менә ул дога:

اَيِبُونَ تَائِبُونَ عَابِدُونَ لِرَبِّنَا حَامِدُونَ.

**«Әәйибүүнә, тәәәибүүнә, гәәбидүүнә лираббинәә хәәмидүүн».**

*«Без кире кайтабыз, тәүбә итәбез, гыйбадәтләребездә Раббымызга даими мактаулар әйтәбез» (Мөслим, 4/105).*

Габдуллаһ ибне Гомәр (Аллаһ аннан риза булсын!) тапшырганча, Аллаһ Расүле, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, сәфәрдән кайтып килгәндә, юлдагы һәр калкулыкка менеп, өч йөз тапкыр «Аллаһу әкбәр» дип әйткән. Аннан соң шушы доганы кыла торган булган:

لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ. لَهُ الْمُلْكُ وَ لَهُ الْحَمْدُ وَ هُوَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ. اَيِبُونَ إِنْ شَاءَ اللهُ تَائِبُونَ,

عَابِدُونَ لِرَبِّنَا حَامِدونَ. صَدَقَ اللّٰهُ وَعْدَهُ وَ نَصَرَ عَبْدَهُ وَ هَزَمَ الْأَحْزَابَ وَحْدَهُ.

**«Ләәә иләәһә илләллааһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Ләһү-ль мүлкү үә ләһү-л хәмду үә һүүә гәләә күлли шәй-иң кадиир. Әәйибүүнә, тәәәибүүнә, гәәбидүүнә лираббинәә хәәмидүүн. Садәкаллаһү үәгьдәһү үә нәсара гәбдәһү үә һәзәмә-ль әхзәәбә үәхдәһ».**

*«Аллаһтан башка һичбер илаһ юк. Аның һичбер тиңдәше юк. Ул барча галәмнең хуҗасы. Аңа мактау. Ул һәрбер эшне булдыра ала! Без кайтабыз, тәүбә кылабыз, Ходаебызга гыйбадәт кылабыз, Аңа мактауларыбызны әйтәбез! Аллаһ Тәгалә Үзенең вәгъдәсен үтәде, Үзенең колына ярдәм итте, бер Үзе кавемнәрне җимерде!» (Бохари, «Дәгъвәт»: 52).*

## Зәкәрийя галәйһиссәламнең догалары

Болар Коръән Кәримдә китерелгән догалардан берничәсе:

رَبِّ هَبْ لِي مِنْ لَدُنْكَ ذُرِّيَّةً طَيِّبَةً إِنَّكَ سَمِيعُ الدُّعَاءِ.

www.darul-kutub.com

**«Рабби һәб лии мил ләдуңкә зүрриййәтәң таййибәһ. Иннәкә сәмиигү-д дүгәәә-ә».**

*«Йә, Раббым! Рәхмәтеңнән миңа бер бала бир! Шиксез, Син минем догамны ишетәсең» («Гыймран» сүрәсе, 38 нче аять).*

رَبِّ لَا تَذَرْنِي فَرْدًا وَأَنْتَ خَيرُ الْوَارِثِينَ.

**«Рабби ләә тәзәрнии фәрдәү үә әңтә хайру-ль үәәрисиин».**

*«Йә, Раббым, мине баласыз ялгыз калдырма, Син бит варисләрнең иң хәерлесе!» («Әнбия» сүрәсе, 89 нчы аять).*

رَبِّ هَبْ لِي مِنَ الصَّالِحِينَ.

**«Рабби һәб лии минә-с саалихиин».**

*«Әй, Раббым, миңа бер изге бала бир, миңа ярдәмче булсын!» («Саффат» сүрәсе, 100 нче аять).*

www.darulkutub.com

## Зәкәт бирүчегә укыла торган дога

Исламда зәкәт алучының зәкәт бирүче өчен дога кылуы сөннәт. Аллаһ Тәгалә әйкән: «Расүлем! Әнә шул тәүбә итеп төзәлүчеләрнең малларыннан зәкәт сәдакаларыннан син ал, аларны биргән сәдакалары белән гөнаһларыннан араларсың һәм эшләрен төзәтерсең. Һәм аларга дога кыл. Һичшиксез, синең догаң аларның күңеленә карар, Аллаһ ишетүче һәм белүче» («Тәүбә» сүрәсе, 103 нче аять).

## Зәкәт биргән кеше өчен кылына торган дога:

اللَّهُمَّ صَلِّ عَلَيْهِ.

**«Әллааһүммә салли галәйһ».**

*«Йә, Аллаһым! Аңа рәхмәтеңне иңдер» (Бохари: 7/157).*

www.darul-kutub.com

## Зәмзәм суын эчкәндә әйтелә торган дога

اللَّهُمَّ إِنِّ أَسْأَلُكَ عِلْمًا نَافِعًا وَ رِزْقًا وَاسِعًا وَ شِفَاءً مِنْ كُلِّ دَاءٍ.

**«Әллааһүммә инниии әсь-әлүкә гильмән нәәфигәү үә ризкау үәәсигәү үә шифәәә-әм миң күлли дәәә-э».**

*«Йә, Аллаһым! Синнән файдалы гыйлем, киң ризыклар һәм һәртөрле авырулардан шифа бирүеңне телим».*

## Байлыкның коткысыннан Аллаһка сыгыну өчен укыла торган дога

Бу дога Аллаһ Расүле, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, өйрәткән догалардан берсе:

اللَّهُمَّ إِنِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ النَّرِ وَ مِنْ عَذَابِ النَّارِ
وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْقَبْرِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابِ الْقَبْرِ

www.darul-kutub.com

وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْغِنَى وَ أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْفَقْرِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْمَسِيحِ الدَّجَّالِ.

**«Әллааһүммә иннии әгүүзү бикә миң фитнәти-н нәәри үә мин гәзәәби-н нәәри үә әгүүзү бикә миң фитнәти-ль кабьри үә әгүүзү бикә мин гәзәәби-ль кабьри үә әгүүзү бикә миң фитнәти-ль гыйнәә үә әгүүзү бикә миң фитнәти-ль фәкъри үә әгүүзү бикә миң фитнәти-ль мәсиихи-д дәҗҗәәл».**

*«Йә, Аллаһым! Утның коткысыннан һәм газабыннан Сиңа сыенам. Кабернең коткысыннан һәм газабыннан Сиңа сыенам. Байлыкның коткысыннан һәм фәкыйрьлекнең коткысыннан Сиңа сыенам. Ялган Мәсих (мессия) Дәҗҗалның коткысыннан Сиңа сыенам» (Бохари: 7/161).*

## Зөфаф догасы

Гамр ибне Шөгайб тапшырганча, Мөхәммәд, салләллаһу галәйһи үәсәлләм, әйткән:

«Берәрегез өйләнгәндә, хатынының



www.darul-kutub.com

маңгаеннан тотсын да шушы доганы әйтсен:

اللَّهُمَّ إِنِّ أَسْأَلُكَ خَيْرَهَا وَ خَيرُ مَا جَبَلْتَهَا عَلَيْهِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا وَ شَرِّ مَا جَبَلْتَهَا عَلَيْهِ.

**«Әллааһуммә инниии әсь-әлүкә хайраһәә үә хайра мәә җәбәлтәһәә гәләйһи үә әгүүзү бикә миң шәрриһәә үә шәрри мәә җәбәлтәһәә гәләйһ».**

*«Йә, Аллаһым! Хакыйкатьтә, мин Сине аның хәерле булуын һәм Син аны бар иткәнеңнең хәерле булуын сорыйм. Сиңа аның явызлыгыннан һәм аны бар иткәнеңнең явызлыгыннан ялварам» (Хәким: 2/186).*

## Золымга каршы кылына торган дога

Бу дога Коръән Кәримдә Аллаһ Тәгалә тарафыннан өйрәтелгән догалардан берсе.

Мәзлумнарның залимнәр хаксызлыгыннан Аллаһка ялварган догалары:

رَبَّنَآ أَخْرِجْنَا مِنْ هَذِهِ الْقَرْيَةِ الظَّالِمِ أَهْلُهَا ج وَاجْعَل لَنَا مِنْ لَدُنْكَ وَلِيًّا وَاجْعَل لَنَا مِنْ لَدُنْكَ نَصِيرًا ط



www.darul-kutub.com

**«Раббәнәәә әхъриҗнәә мин һәәзиһи-ль карьйәти-з заалими әһлүһәә үәҗгәл ләнәә мил ләдүңкә үәлийййәү үә җгәл ләнәә мил ләдүңкә нәсыыйра».**

*«Әй, Раббыбыз, хуҗалары залим булган шәһәрдән безне чыгар. Безне залимнәр кулыннан коткаручы бер вәли бир һәм үз хозурыңнан безгә ярдәм дә бир» («Ниса» сүрәсе, 75 нче аять).*

## Золым һәм имансызлыкка каршы кылына торган дога

Бу доганы Аллаһ Тәгалә Коръән Кәримдә өйрәткән. Аны Хәзрәти Муса галәйһиссәламнең Фиргавеннең золымыннан үзенә һәм кардәшенә ярдәмче булмаган фасикъ кавеменә каршы кылган догасы:

رَبِّ إِنِّ لَآ أَمْلِكُ إِلَّا نَفْسِى وَأَخِى فَافْرُقْ بَيْنَنَا وَبَيْنَ الْقَوْمِ الْفَاسِقِينَ.

www.darulkutub.com

**«Рабби инниии ләәә әмликү илләә нәфсии үә әхый фәфрукъ бәйнәнәә үә бәйнә-ль кауми-ль фәәсикыйн».**

*«Әй, Раббым, мин фәкать үземә һәм кардәшем Һарунга ихтыярлымын, башкаларга һич сүзем үтмидер. Йә, Раббым, фасикъ кавым белән безнең араны аер» («Маидә» сурәсе, 25 нче аять).*

www.darul-kutub.com

СОДЕРЖАНИЕ

КЕРЕШ СҮЗ .......................................................... 3

Пәйгамбәребез Сөннәтендәге догалар .................... 7

**Дога төрләре** ............................................................ 11

1. Шөкер догасы ........................................................ 11

2. Үтенү һәм теләү догасы ....................................... 14

3. Аллаһтан гафу сорау
(истигъфар) догасы ................................................. 15

4. Гыйбадәт һәм мактау догасы................................ 18

5. Башка мөселманнар өчен
кылынган догалар ..................................................... 21

**Тәһарәт догалары** .................................................. 23

*1. Тәһарәт ала башлаганчы
укыла торган дога:* ................................................... 26

*2. Авызга су алганда әйтелә:*.................................. 26

www.darul-kutub.com

*3. Борынга су алганда укыла:*................................ 26

*4. Битне юганда әйтелә:*........................................ 27

*5. Уң кулны юганда укыла:*....................................... 27

*6. Сул кулны юганда укыла:*...................................... 28

*7. Башка мәсех кылганда укыла:*.............................. 28

*8. Колакларны мәсехләгәндә укыла:*........................ 28

*9. Муенны мәсехләгәндә укыла:*............................... 29

*10. Аякларны юганда әйтелә торган дога:*.............. 29

Авырганда яки сызланганда укыла торган дога .. 30

Ахшам намазына азан ишеткәч
укыла торган дога ................................................. 30

Ахшам намазыннан соң укыла торган дога.......... 31

Төчкергәч әйтелә торган дога ................................ 31

Тау куышы кешеләре (әсъхәәбү кәһф) догасы ..... 32

Баш авырткanda укыла торган дога...................... 33

Бәлагә тарыган кешене күргәч
әйтелә торган дога.................................................. 34



www.darul-kutub.com

Йөкташу хайваны яки машина сатып алгач
укыла торган дога .................................................. 34

Мәчеткә кергәндә укыла торган дога.................... 35

Мәчеттән чыкканда әйтелә торган дога................ 36

Җеназа күргәндә укыла торган дога ..................... 37

Саранлыктан котылу өчен
кылына торган дога.................................................. 37

Җенси мөнәсәбәткә кергәнче
укыла торган дога .................................................. 38

Җомга иртәсендә укыла торган дога..................... 39

Дәҗҗал фетнәсеннән саклану өчен
укыла торган дога .................................................. 39

Җир тетрәгәндә укыла торган дога ...................... 40

Диндә нык булу өчен укыла торган дога ............. 41

Теш сызлаганда укыла торган дога ...................... 41

Куллар юганда укыла торган дога ........................ 42

Кием кигәндә укыла торган дога........................... 43

Өйдән чыкканда укыла торган дога ..................... 44

www.darul-kutub.com

Өйгә кергәндә укыла торган дога ......................... 45
Бала сорап укыла торган дога ............................. 46
Яңа өйләнешүчеләргә укыла торган дога ............ 46
Әюб галәйһиссәламнең догалары ........................ 47
Азаннан соң укыла торган дога ............................ 48
Көймәгә утырганда укыла торган дога ................ 49
Кияү белән кәләш бүлмәсенә кергән ир
укырга тиеш дога .................................................. 50
Сугышта дошманны җиңү өчен
укыла торган дога .................................................. 50
Авырудан сәламәтләнү өчен
укыла торган дога .................................................. 51
Бәдрәфкә кергәндә укыла торган дога ................. 52
Бәдрәфтән чыкканда укыла торган дога ............... 53
Һидаятькә һәм тәкъвалыкка ирешү өчен
кылына торган дога................................................ 53
Истихарә догасы.................................................... 54
Итәгатьле мөселманнар догасы ............................ 56

www.darul-kutub.com

Игелекле гамәлләргә ирешү өчен
кылына торган дога.............................................57

Кадер-хөрмәткә һәм дәрәҗәләргә ирешү өчен
укыла торган дога ................................................58

Кабер газабыннан котылу өчен
укыла торган дога ................................................59

Кадер кичәсендә укыла торган дога........................59

Куркыныч төш күргәч укыла торган дога ............60

Әхлакны дөресләү өчен кылына торган дога.......61

Корбан чалучы кеше әйтә торган дога.................62

Корбан чалганчы аягүрә басып
укыла торган дога ................................................62

**Намаз эчендә укыла торган кайбер сүрәләр**....64

«Фатиха» сүрәсе.....................................................64

«Аятель Көрси» .....................................................65

«Фил» сүрәсе ..........................................................67

«Кораеш» сүрәсе ....................................................68

www.darul-kutub.com

«Магун» сүрәсе .......................................................... 69
«Кәүсәр» сүрәсе ........................................................ 70
«Кәфирун» сүрәсе ...................................................... 71
«Насыр» сүрәсе .......................................................... 72
«Мәсәд» сүрәсе .......................................................... 73
«Ихлас» сүрәсе ........................................................... 74
«Фәләкъ» сүрәсе.......................................................... 75
«Нәс» сүрәсе ................................................................ 76

**Намаз эчендә укыла торган кайбер догалар** ... 77
«Әт-Тәхиййәт» ........................................................... 77
«Салават» ..................................................................... 78
«Раббәнә әтинә» ......................................................... 79
Кунут догалары .......................................................... 81
Намаздан соң укыла торган догалар ..................... 84
Намаздан соң укыла торган тагын бер дога ......... 88
Намаздан соң укыла торган тагын бер дога ......... 89

www.darul-kutub.com

Күз тиюдән саклану өчен укыла торган дога ....... 90

Күз тимәсен өчен тагын бер дога ......................... 91

Рәҗәп ае башлангач укыла торган дога ................ 92

Җил искәндә укыла торган дога ............................ 92

Иртәнге намазлардан соң укыла торган дога ...... 93

Салават-и Мөнҗия ................................................. 94

Салават-и Тәфриҗия.............................................. 96

Салават-и Уммия ................................................... 97

Салават-и Фәтхия .................................................. 97

Сәййидү-ль Истигъфар.......................................... 98

Йокларга яткач укыла торган дога ...................... 100

Йокыдан уянгач укыла торган дога.................... 102

Ризык догалары .................................................... 103

Яңа туган баланың колагына
әйтелә торган дога................................................ 107

Яңа кием кигәндә әйтелә торган дога ................ 108

Йолдыз атылганда укыла торган дога................ 109

www.darul-kutub.com

Юлга чыгучы кеше кыла торган дога ................ 109

Юлда чакта кунарга туктаганда
укыла торган дога ................................................ 110

Юлдан кайткач кылына торган дога................... 110

Зәкәрийя галәйһиссәламнең догалары............... 112

Зәкәт бирүчегә укыла торган дога...................... 114

Зәкәт биргән кеше өчен кылына торган дога: .... 114

Зәмзәм суын эчкәндә әйтелә торган дога ........... 115

Байлыкның коткысыннан Аллаһка
сыгыну өчен укыла торган дога.......................... 115

Зөфаф догасы....................................................... 116

Золымга каршы кылына торган дога.................. 117

Золым һәм имансызлыкка каршы
кылына торган дога............................................. 118

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com